# Түгәрәк уен

ТАТАР ХАЛЫК ИҖАТЫН ЯКТЫРТУЧЫ МӘГЪЛҮМАТИ-ПОПУЛЯР АЛЬМАНАХ

2/ 2025

**«...Ә төнлә театр стеналары тышкы яктан яктыртыла башлагач, аның тоташ үтә күренмәле пыяла алгы өлеше аша балкып торучы алтын стеналарны күрергә була. Бу су катламы астындагы хәзинә балкышын хәтерләтә, әйтерсең лә, театр үзе хәзинә – Кабан күле хәзинәсе...»**




KAZAN FORUM
13-18 МАЯ 2025
KAZANFORUM


KAZAN FORUM






# Татарстан осталары – «Россия – ислам дөньясы» икътисад форумында

**2025 елның 14-16 маенда Казанда халыкара зур чара – «Россия – ислам дөньясы» XVI Халыкара икътисад форумы булып узды. Әлеге чараның программасы гаять бай иде. Анда 103 ил һәм Россия Федерациясенең 82 регионы катнашты. Форум кысаларында 46 эшлекле программа сессиясе үтте, 19 килешүгә кул куелды, 7 илдән килгән 8 дизайнер Modest Fashion Dayга үз коллекцияләрен тәкъдим итте.**

15 майда Казанда Ислам хезмәттәшлеге оешмалары илләре мәдәният министрларының беренче съезды да булып узды. Анда Ислам хезмәттәшлеге оешмасының 15 иленнән килгән вәкилләр катнашты. Очрашуның төп темасы – күпкырлы дөньяда бердәйлекне һәм күптөрлелекне саклау буларак мәдәни алмашу иде.

Съездда Россиянең мәдәният министры Ольга Любимова катнашты. Ул хезмәттәшлекнең мөһимлеген ассызыклады һәм ислам дөньясының 2026 елда мәдәни башкаласы итеп сайланган Казанда булачак яңа очрашуларга зур өмет баглавын белдерде. Әлеге очрашу Казан Ратушасында үтте.

Казанның Халыкара «ЭКСПО» күргәзмә үзәгендә «Россия – ислам дөньясы» XVI Халыкара икътисад форумы кысаларында Татарстан Республикасының халык сәнгате һөнәрләре осталары эшләнмәләре ярминкәсе һәм күргәзмәсе дә оештырылды. Бик күп чит ил кунаклары Татарстанның халык сәнгате һөнәрләре осталарының уникаль эшләнмәләре белән кызыксындылар.

**Фоторәсемнәр Татарстан Республикасының мәдәният өлкәсендә инновацияләр һәм традицияләр саклау ресурс үзәге архивыннан**

# Эчтәлек


**ТАТАР ДӨНЬЯСЫНЫҢ ТРАДИЦИОН МӘДӘНИЯТЕ ЯҢАЛЫКЛАРЫ**



4 **Рөстәм Миңнеханновка «Татарстан Республикасы милли музее тупланмасындагы татар костюмы» альбомын тәкъдим иттеләр**

6 **«Сабантуй халык бәйрәмен оештыру һәм үткәрү методикасы һәм технологиясе»**

8 **Баку шәһәрендә Халыкара келәм фестивале үткәрелде**

10 **Татарстанның мәдәни башкаласы – Әтнә районы**

**СӘНГАТЬ**



12 Н. Кумысникова
**Кабан күле хәзинәсе**

**ҺӨНӘРЛЕ ҮЛМӘС...**



22 Р. Галләм
**Тимергә җан җылысы өрүче осталар...**

**ӘДӘБИ МИРАС**

26 Л. Мөхәммәтҗанова
**Дәһшәтле чорның ышанычлы юлдашлары**



**Түгәрәк уен**
№2 (56 ) / 2025


*Халык зур ул, көчле ул, дәртле ул,*
*моңлы ул, әдип ул, шагыйрь ул.*
*Г. Тукай*


16+ Татар халык иҗатын яктыртучы мәгълүмати-популяр альманах

**Гамәлгә куючылар:**
Татарстан Республикасы
Мәдәният министрлыгы каршындагы
Татарстан Республикасының мәдәният өлкәсендә инновацияләр һәм традицияләр саклау ресурс үзәге

**Редколлегия:**
Ирада Әюпова
Марсель Бакиров
Тәлгат Галиуллин
Дания Заһидуллина
Марс Тукаев
Фәрит Юсупов

**Директор:**
Алсу Равил кызы Мифтахова
**Баш мөхәррир:**
Рәзинә Әхтәм кызы Исмәгыйлева

**Альманахның иҗат төркеме:**
Гөлназ Латыйпова
Илнара Гәрәева

**Дизайнер һәм биткә салучы**:
Диләрә Нәүрузова

Альманах 2020 елның 13 ноябрендә элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр даирәсендәге күзәтчелек буенча Федераль хезмәт идарәсендә (Роскомнадзор) теркәлгән. Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС77-79590. Журнал өч айга бер чыга. Бәясе ирекле.

Кәгазь форматы 60×90 ⅛.
Күләме 8 басма табак.
Басарга кул куелды: 17.06.2025
Чыгу көне: 26.06.2025
Заказ: №178. Тираж: 1000 экз.

Редакция һәм нәшер итүче:

420021, Казан, Тукай ур., 74 а.
Хатлар язар өчен адрес:
420015, Казан, Пушкин ур., 66/33
тел.: 293-27-99.
E-mail: tugarakuen@mail.ru

Отпечатано в ИП Селиванова А.Г.
420015, Казань, Галактионова, 14
тел.: +7(843)2382449
E-mail: Orange_k@list.ru


Кульъязмаларга бәя бирелми, алар кире кайтарылмый.
Күчереп басканда, «Түгәрәк уен» альманахына сылтама ясау мәҗбүри.

**Тышлыкта:** Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры диварларындагы бизәкләр фрагментлы.
**Рәссам Наилә Кумысникова**


© «Түгәрәк уен», 2025

2025 ЕЛ – ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНДА ВАТАННЫ САКЛАУЧЫ ЕЛЫ



32 Л. Хәкимова
**Хәрби хезмәткә озату**

МИФОЛОГИК МИРАС

36 Г. Гыйльманов
**Әфсеннәр – дөньялык белән аралашу теле**

ХАЛКЫБЫЗНЫҢ КҮРКӘМ БӘЙРӘМНӘРЕ



40 Л. Мөхәммәтгалиева
**Ат тоягы кыздыру**

СӘЯХӘТНАМӘ



43 Э. Сәлахова
**Галимнәребез сукмагыннан Төркестанга сәяхәт**

БЕЗГӘ ЯЗАЛАР

50 Р. Закирова
**Без чигәбез асыл җепләр белән**

БЕЗНЕҢ КИТАПХАНӘ




52 **Күңгә күренмәс сылу-көмеш**

БЕЗ, БЕЗ, БЕЗ ИДЕК...



56 Г. Зәйнакова, Р. Гарифуллина
**«Туган нигезгә җыелу» йоласы**

58 **Бабам портреты**
*(җыр)*

ӨЙ КҮРКЕ – АШ



59 **Азык, ризык, аш-су төрләре турында мәкальләр**

60 **Яшел аш**

ЯЛ СӘГАТЬЛӘРЕНДӘ

62 **Бергәләп бизибез!**

# Рөстәм Миңнехановка «Татарстан Республикасы милли музее тупланмасындагы татар костюмы» альбомын тәкъдим иттеләр

**2025 елның 26 апрелендә – Туган тел көнендә Татарстан Республикасы Рәисе Рөстәм Миңнехановка «Татарстан Республикасы милли музее тупланмасындагы татар костюмы» альбомын тәкъдим иттеләр.**

Бу матур бизәкле һәм эчтәлекле китап Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институты (этнологик тикшеренүләр бүлеге), Татарстан Республикасы Милли музее, Татарстан Республикасының мәдәният өлкәсендә инновацияләр һәм традицияләр саклау ресурс үзәге, «БЮРО БАНУ» остаханәсе белгечләре һәм декоратив-гамәли сәнгать осталары, «Заман» нәшрияты тарафыннан хәзерләнде.

Альбомда XIX гасырның икенче яртысы – XX гасырның башында яшәгән төрле буын шәһәр татар гаиләләренең чын кием үрнәкләре тәкъдим ителгән. Кием комплекслары Татарстан Республикасы Милли музее фондының артефактлары (баш киемнәре, эчке һәм тышкы киемнәр, аяк киемнәре, бизәнү әйберләре) нигезендә эшләнгән.

Китап укучыларны кием тарихы һәм Россиядәге татар халкының мәдәни байлыгын һәм гаилә кыйммәтләрен ачып бирүче иң зур музей коллекциясе белән таныштыра. Басманың уникальлеге кием, өлгеләр, аерым предметларның методик текстлары һәм технологик карталарының фотосурәтләрен бастырудан гыйбарәт. Китап этнографларга, мәгариф һәм мәдәният хезмәткәрләренә, модельерларга, дизайнерларга, Россия халыклары тарихы һәм мәдәнияты белән кызыксынучы барлык кешегә адресланган.







# «Сабантуй халык бәйрәмен оештыру һәм үткәру методикасы һәм технологиясе»




**Быелның 14 апреленнән 18 апреленә кадәр Казанда Россиянең төрле төбәкләреннән һәм чит илләрдән килгән Сабантуйны оештыручылар өчен «Сабантуй халык бәйрәмен оештыру һәм үткәру методикасы һәм технологиясе» дигән семинар-практикум эшләде. Аны Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты һәм Татарстанның мәдәният ресурс үзәге белән берлектә оештырды.**

Семинар-практикум ел саен уздырыла һәм катнашучыларның географиясе елдан-ел киңәя бара. Быелгы чарада Россия Федерациясенең 24 төбәгеннән һәм 2 чит илдән 40 кеше катнашты. Семинарда катнашучылар арасында Владимир, Волгоград, Калининград, Кемерово, Киров, Курган, Түбән Новгород, Новосибирск, Омск, Оренбург, Пенза, Свердловск, Томск, Төмән, Чиләбе, Ленинград, Мәскәү, Мурманск өлкәләреннән, Пермь, Красноярск, Краснодар якларыннан, Коми Республикасы, Удмуртия Республикасы, Саха Республикасы (Якутия), Казахстаннан вәкилләр бар иде.

Чараның рәсми ачылышы башкалабызның Каюм Насыйри музеенда узды. Семинарда катнашучыларны Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Разил Зиннәтуллин һәм Каюм Насыйри музее директоры Кадрия Хәлимова сәламләде.

Тарих фәннәре кандидаты, Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институтының яңа тарих бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре Бәхтияр Измайлов «Сабан туе: тарих һәм заманча үзгәрешләр» дигән темага чыгыш ясады.

Семинарда катнашучылар өчен Каюм Насыйри музее буенча кызыклы экскурсия дә оештырылды.



Семинарның икенче көнендә фотограф, Татарстан Республикасы Журналистлар берлеге әгъзасы Рәисә Сафиуллина Сабантуйга хәзерләнү һәм үткәрү чорында массакүләм матбугат чаралары белән үзара бәйләнеш серләрен ачты; «Ак калфак» иҗтимагый оешмасы рәисе Кадрия Идрисова – бәйрәмнең аерылгысыз өлеше булган уен ярышлары, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Сәнгать белеме үзәге хезмәткәре Айгөл Җәләлиева – декоратив-гамәли



сәнгать күзлегеннән чыгып караганда, Сабантуй бәйрәменең милли мәйданчыгындагы осталар тудырган халык сәнгать эшләнмәләре, спорт ярышларын оештыручы һәм продюсер Айдар Шәймәрданов милли көрәш һәм аның бәйрәм кысаларындагы әһәмияте турында сөйләде; ә КБ MON генераль директоры Азат Галләмшин бәйрәмне оештыру серләре белән бүлеште.

«Сабатуй халык бәйрәмен оештыру һәм үткәрү методикасы һәм технологиясе» семинар-практикумының өченче көнендә анда катнашучылар бәйрәмнең этномәдәни бизәлеше белән бәйле күп кенә әһәмиятле темалар турында фикер алыштылар. Әлеге теманың башында педагогика фәннәре кандидаты, Казан дәүләт мәдәният институтының этносәнгать иҗаты һәм музыкаль белем бирү кафедрасы профессоры һәм доценты Алсу Еникеева торды. Аннары BURO BANU брендының дизайнеры һәм нигез салучысы Элара Шәйхи татар костюмы турында сөйләде, ә «Мишәрләр» балалар фольклор-этнографик коллективның яшь артистлары Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының программа проектлары кысаларында төзелгән сәхнә киемнәре комплексын күрсәттеләр.

17 апрель көнне семинарда катнашучылар Татарстан Республикасының Биектау районында булды. Биредә алар татар милли бәйрәменең прологы белән танышып, мич коймагы һәм күн мозаикасы буенча остаханәләрдә катнаштылар. Шулай ук Ямаширмә авылындагы халык һөнәрләре һәм декоратив-гамәли сәнгать музеена һәм Өбрә авылындагы Салих Сәйдәшев музеена экскурсия оештырылды. Семинар тәмамланганнан соң, катнашучыларга сертификатлар һәм квалификация күтәрү турында таныклыклар тапшырылды.






# Баку шәһәрендә Халыкара келәм фестивале үткәрелде

Бу елның май аеның беренче көннәрендә Азәрбайҗан Республикасының Баку шәһәрендә Халыкара келәм фестивале үткәрелде, ул келәм сәнгатен бәяли белүче бөтендөнья осталарын һәм рәссамнарын үзенә җыйды.



Фестивальнең төп максаты Азәрбайҗанның гаять зур масштабтагы келәм туку сәнгатен популярлаштыру, аның бай мирасын һәм үсеш юлларын күрсәтү, һәм шулай ук бөтен дөньядан җыелган осталар белән тәҗрибә уртаклашу иде.

Бу чарада Татарстан Республикасы осталары да катнашты. Алар «Өч татар келәме» креатив лабораториясен тәкъдим иттеләр.

Узган елның сентябрендә Мәдәни инициативаларның Президент фонды ярдәме белән әлеге фондны гамәлгә ашыру кысаларында «Азерхалча» ААҖ остасы һәм эксперты Татарстан осталары өчен йон келәм эшләнмәләре җитештерү буенча өйрәнүләр үткәргән иде. Ә быелның 3 маенда республикабызның фестивальгә җавап визиты буларак чакырылган делегациясе әлеге өйрәнүләрне презентацияләде.

«Ичеришехер» Дәүләт тарихи-архитектура тыюлыгының фестиваль мәйданчыгында Татарстан Республикасы стендын татар орнаментлары төшерелгән өч төрле келәм бизәп торды.





Халыкара келәм фестивале быел Ичеришехерның ЮНЕСКО Бөтендөнья мирасы исемлегенә кертелүенең 25 еллыгы һәм Азәрбайҗанның традицион келәм туку сәнгатенең ЮНЕСКО матди булмаган мәдәни мирасы исемлегенә кертелүенең 15 еллыгына туры килде.

«Азерхалча» ААҖ идарәсе рәисе, Азәрбайҗанның атказанган сәнгать эшлеклесе Эмин Мамедов фестивальнең республикада ел саен 5 майда билгеләп үтелә торган профессиональ бәйрәм – «Келәм тукучылар көне»нә багышлануын билгеләп үтте.

# Татарстанның мәдәни башкаласы – Әтнә районы

Татарстанда иң зур мәдәни конкурсларның берсе – «Татарстанның мәдәни башкаласы» республика конкурсы тәмамланды.

Конкурс Гаилә елы эгидасы астында узды, ул традицион гаилә кыйммәтләрен үзешчән коллективлар һәм артистларның иҗади чыгышлары аша күрсәтүгә юнәлдерелгән иде. Шулай ук патриотизм темасына да аерым игътибар бирелде. Билгеле булганча, «Татарстан Республикасының мәдәни башкаласы» фестиваль-конкурсы Татарстан Республикасы Рәисе Р.Н. Миңнеханов йөкләмәсе буенча уздырыла. Бу чара ел саен Татарстанның мәдәни тормышында әһәмиятле вакыйгага булып тора.

Әлеге чара кысаларында республикабызда яшәүчеләр һәм аның кунаклары Татарстандагы 35 муниципаль оешманың уникаль милли традицияләре, гореф-гадәтләре һәм казанышлары белән таныша алдылар. Конкурс 20000нән артык катнашучыны берләштерде, алар арасында 500 эшмәкәр һәм 608 иҗат коллективы бар иде. Чара онлайн-форматта 1 миллионнан артык тамашачыны үзенә җәлеп итте.

Конкурсның җиңүчеләре 2025 елның 3 маенда игълан ителде. Бүләкләү республиканың Хөкүмәт йортында традицион киңәшмәдә узды. Бүләкләрне Татарстан Республикасы Премьер-министры Алексей Песошин тапшырды.

Татарстан Республикасының 2025 елгы мәдәни башкаласы итеп Әтнә муниципаль районы танылды.

Конкурс кысаларында муниципаль районнар арасында биш категориядә җиңүчеләр билгеләнде.






**Халык саны 21 мең кешегә кадәр:**

I дәрәҗә лауреат: Теләче муниципаль районы;

II дәрәҗә лауреат: Чирмешән муниципаль районы;

III дәрәҗә лауреат: Кайбыч муниципаль районы.

**Халык саны 21 меңнән 35 мең кешегә кадәр:**

I дәрәҗә лауреат: Баулы муниципаль районы;

II дәрәҗә лауреат: Аксубай муниципаль районы;

III дәрәҗә лауреат: Балтач муниципаль районы.

**Халык саны 35 меңнән 60 мең кешегә кадәр:**

I дәрәҗә лауреат: Кукмара муниципаль районы;

II дәрәҗә лауреат: Азнакай муниципаль районы;

III дәрәҗә лауреат: Арча муниципаль районы.

**Халык саны 60 мең кешедән күбрәк:**

I дәрәҗә лауреат: Яшел Үзән муниципаль районы;

II дәрәҗә лауреат: Түбән Кама муниципаль районы;

III дәрәҗә лауреат: Чистай муниципаль районы.

**«Патриотик тәрбиягә керткән өлеше өчен» номинациясе:**

Мамадыш муниципаль районы;

Чүпрәле муниципаль районы;

«Татарстанның мәдәни башкаласы» конкурсы җәмгыятьнең традицион кыйммәтләр һәм мәдәни мирас тирәсендә туплануына ачык мисал булды, бу, һичшиксез, республикабыз мәдәни тормышының алга таба үсешенә ярдәм итәчәк.

**Яңалыклардагы фоторәсемнәр Татарстан Рәисе рәсми сайтыннан һәм Татарстан Республикасының мәдәният өлкәсендә инновацияләр һәм традицияләр саклау ресурс үзәге архивыннан**

# Кабан күле ХӘЗИНӘСЕ

**Наилә Кумысникова,**
*Татарстанның халык рәссамы*





*...Шул вакыт ханнар, вәзирләр качтылар,*
*Барча малны ушбу күлгә сачтылар.*
*Сачтылар алтын-көмешнең һәммәсен,*
*Ягъни «безнең мал кешегә калмасын».*
*Шул заманнан бирле, кем, алтын-көмеш*
*Күл төбендә һич хисапсыз күп, имеш.*

***Г. Тукай.***

**Берничә ай дәвамында Казан халкы Галиәсгар Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрының яңа бинасы өчен иң яхшы проектка архитекторларның халыкара конкурсын күзәтте. Башкача булуы да мөмкин түгел. Татар үзәге – милли мәдәният үзәге, берничә буын казанлыларның яраткан урыны.**



Горький урамында урнашкан театрның уңайлы бинасы нәкъ менә шундый иде, минем балачагым шунда узды, әнием – күренекле актриса, Габдулла Тукай исемендәге премиянең беренче лауреаты Асия Хәйруллина шуның сәхнәсендә уйнады, хәтта мин дә «Муса Җәлил» спектаклендә шагыйрьнең кызы Чулпан ролен башкардым. Соңрак, узган гасырның 80нче елларында Татарстан урамындагы бина үзенә тартып торучы шундый үзәк булып китте. Вакытлар уза, буыннар алмашына, яңа идеяләр барлыкка килә, заманнар үзгәрә, алар белән бергә без дә үзгәрәбез.

Конкурста Россиянең Ваухаус бюросы (Мәскәү) вакытлы берләшмәсе һәм Япониянең дөньякүләм танылган архитекторы Кенго Кума студиясе җиңеп чыкты. Проект турында фикер алышу, яңа бинаның урыны, бу төзелешнең максатчанлыгы кайнар бәхәсләр, дулкынланулар тудырды. Болар миңа да кагылды – булачак театр интерьерларының 3D сурәтләре белән танышканда, рәссам өчен анда «татар аһәңе» табуның катлаулы булачагы, ләкин аның һичшиксез табылырга тиешлеге турында уйландым. Вакытлар узды, минем фикерләүләрем акрынлап онытылды, уйларымны башка мәшәкатьләр алыштырды.

Кайвакыт тормышның гаҗәеп сюрпризлар ясап куюына гаҗәпләнми мөмкин түгел. Театр интерьерын бизәүдә катнашырга чакырулары минем өчен менә шундый көтелмәгән хәл булды.

Россия-Япония архитекторлары берләшмәсенең төп принципы – кеше һәм әйләнә-тирәлек арасындагы гармонияне эзләү. Яңа театр бинасының тышкы йөзен төзелеш өчен ниятләнгән урын белән бәйләү мөһим иде. Бу – Кабан күле һәм Иске Татар бистәсе тирәсе. Кенго Кума тышкы архитектура формасы итеп Кабан күлендә «ачыла» торган «боз чәчкәләр»не алган, аның төп идеясе – бинаның тышкы салкын структурасы һәм җылы, уңайлы эчке пространствосы.

Озакламый мин Мәскәүнең Ваухаус бюросы архитекторлары белән таныштым. Миңа булачак театрның планын җибәрделәр, бурычымны аңлаттылар. Бу гади генә эш түгел иде, миңа улым – тәҗрибәле дизайнер Җәмил Федотов булышты. Һәм без бергәләп эшләргә карар кылдык.

Башта бизәлешнең төп эшкә аерым бер мәгънә бирә торган гомуми идеясен билгеләргә кирәк иде. Архитекторлар кебек үк, без дә эшне театр бинасы урнашачак урыннан – Кабан күле яры буеннан башларга булдык. Мин 1552 елда Казанны алганда күл төбенә яшерелгән иксез-чиксез хан хәзинәләре турында буыннан-буынга сөйләнеп килүче борынгы риваятьне искә төшердем. Булган хәлме бу, әллә уйдырмамы, ни булса да, 500 елга якын инде ул казанлылар күңелендә яши.

Ул байлыкларны эзләп табарга тырышучылар да булган – бу турыда Рафаэль Мостафинның узган гасырның 90нчы елларында чыккан «Кабан күле» дигән китабында бик тәэсирле итеп язылган. Анда хәзинәнең нәрсәләрдән торганы да тасвирланган: төрле чорда яшәгән халыкның алтын һәм көмеш тәңкәләре, кыйммәтле сугыш киемнәре, затлы ташлар белән бизәлгән кораллар, хатын-кызларның бизәнү әйберләре. «Анда күп нәрсә булган! Сезнең төшегезгә дә кермәгән әйберләр...» – ди әсәр герое, үзен Исмәгыйль Азимов дип таныштырган карт (ул гаиләбезнең ерак кардәше булып чыкты).

Бу образ безне үзенә җәлеп итте, һәм фойены бизәгәндә «Кабан күле хәзинәләре» концепциясен тәкъдим итәргә, стеналарны бизәкләп кенә түгел, «хәзинәләр белән баетып» ясарга булдык. План буенча фойеның зур пространствосын өч зур зал берләштерә. Аларның һәркайсын түгәрәкләнеп килгән биш стена әйләндереп алган. Барлыгы – 15 стена, һәрберсе 11 метр биеклектә, озынлыклары – 10-30 метр. Һәм аларның барысы да бизәкле булырга тиеш.





*БУ ОБРАЗ БЕЗНЕ ҮЗЕНӘ ҖӘЛЕП ИТТЕ, ҺӘМ ФОЙЕНЫ БИЗӘГӘНДӘ «КАБАН КҮЛЕ ХӘЗИНӘЛӘРЕ» КОНЦЕПЦИЯСЕН ТӘКЪДИМ ИТӘРГӘ, СТЕНАЛАРНЫ БИЗӘКЛӘП КЕНӘ ТҮГЕЛ, «ХӘЗИНӘЛӘР БЕЛӘН БАЕТЫП» ЯСАРГА БУЛДЫК.*









Д.Чебаненко фоторәсеме

# «УНИВЕРСАЛЬ» ЗАЛ

«Универсаль» залның эчендә – кара пространство һәм проекция ярдәмендә спектакль тудыру өчен гаять зур мөмкинлекләре, тавыш яздыру өчен менә дигән акустикасы һәм кино һәм видео төшерергә мөмкинлек бирә торган заманча яктылык җиһазлары. Бу зал стеналары өчен орнаментны без борынгы гомумтөрки стилистикасында эшләргә булдык, кырыс бизәк ритмына батырлык, хәтта сугышчанлык төсмере бирергә тырыштык. Бу композициядә шәһәрне яклаучыларның шлемнарын да, тигез стена рәтләрен дә күрергә була.









## «КӨНЧЫГЫШ» ЗАЛ

«Көнчыгыш» залы стеналарының орнаменты бөтенләй икенче образда. Ул сәхнәнең түгәрәк формасы һәм татар хатын-кызларының милли киеменә хас деталь – монисто хасил итә торган көмешсу тәңкәләрдән төзелгән гөмбәз белән бәйле. Без бу залның стеналарында нәфис, йомшак, матур, кискен контрасттан ерак торган салмаграк орнамент булырга тиеш дип таптык. Бизәкләрендә – Казан күн мозаикасына хас элементлар. Алар 18нче гасыр гүзәлләре яраткан борынгы парча яисә ефәкне хәтерләтә.











А. Артис фоторәсеме

## «ТӨП» ЗАЛ

Өченче, драма спектакльләре өчен билгеләнгән «Төп» зал – иң зурысы, биредә театрның традицион тарихи һәм заманча эчтәлекле төп спектакльләре куелачак. Андагы бизәкләр хатын-кызларның милли бизәнү әйберләре – чулпылар, муенсалар, беләзекләр, асылташлар һәм тәңкәләргә охшатып эшләнде. Нәфислек, җиңеллек, үтә күренмәлелек – бу зал стеналары өчен орнамент стилен Җәмил менә шундый итеп күрде.



Эскизлар расланганнан соң, стеналар нинди материалдан ясалачак, дигән сорау килеп туды. Моның өчен без «хәзинә» образын яхшырак ачу өчен туры килә торган «алтын» һәм «көмеш» металл тәкъдим иттек. Чөнки бары тик металл гына зур, биек стеналарга «җиңеллек» бирә ала иде. Идеябезнең комиссия тарафыннан раслануын зур дулкынлану белән көттек, чөнки бу материалларда 3600 кв. метр зурлыктагы бизәкләрне моңа кадәр беркем дә һәм беркайчан да эшләмәгән әле.

Без «Союз-М» төркемендәге инженер Руслан Фәхретдинов белән таныштык, һәм берничә көннән металлдагы орнаментның беренче үрнәкләре әзер иде инде. Озак кына фикер алышулардан соң, проектыбызны раслау турында карар кабул ителде.

Ваухаус архитекторлары һәм «Союз-М» төркеме инженерлары безнең эскизларны бизәкләре яктыртыла торган күп катлы уникаль паннога әйләндерделәр. Идеябез уңышлы хәл ителде һәм эскизларыбызга төгәл туры килә торган материалда менә дигән итеп гамәлгә ашырылды.

Театр ачылды. Нәкъ без хыялланганча, ул казанлыларны һәм шәһәр кунакларын үзенә тарту үзәгенә әйләнде. Анда инде спектакльләр бара, төрле җыелышлар, форумнар һәм хәтта ярминкәләр уздырыла. Һәркемнең яңа театрны күрәсе килә! Без дә гаиләбез өчен экскурсия оештырырга булдык.



*ТЕАТР АЧЫЛДЫ. НӘКЪ БЕЗ ХЫЯЛЛАНГАНЧА, УЛ КАЗАНЛЫЛАРНЫ ҺӘМ ШӘҺӘР КУНАКЛАРЫН ҮЗЕНӘ ТАРТУ ҮЗӘГЕНӘ ӘЙЛӘНДЕ.*



Онытым – 8нче сыйныф укучысы Ася Федотова аннан алган тәэсирләре белән менә ничек уртаклашты:

*«Яңа театр тамаша урыны гына түгел, ә хәзерге заманның һәм борынгы традицияләрнең үзара кушылуы, чөнки ул Кабан күле хәзинәләре белән турыдан-туры бәйләнгән. Риваять буенча, Казанны Явыз Иван камап алгач, хан казнасы күл төбенә яшерелгән, аның янында бүген театр бинасы калкып утыра. Шуңа күрә театрда бар нәрсә әлеге хәзинәне хәтерләтә: кайбер бизәкләр күл төбендәге кыйммәтле тәңкәләр кебек түгәрәк формалы көмешсыман пластиналар рәвешендә ясалган. Ә алтын төсендәгеләренең орнаментлары Казан татарлары, Идел буе болгарлары һәм ул чорда яшәгән башка милләт халыкларының борынгы бизәнү әйберләрен хәтерләтүче тоташ бер композиция булып күренә. Ә якынрак килсәң, металл челтәр күренә (гаҗәп, ерактан ул бөтенләй күренми) – хәзер инде ул хатын-кызларның бизәнү әйберләре түгел, ә чып-чын сугышчылар көбәсе! Бу – шулай ук Кабан күле төбендә яткан хан казнасының бер өлеше. Ә төнлә театр стеналары тышкы яктан яктыртыла башлагач, аның тоташ үтә күренмәле пыяла алгы өлеше аша балкып торучы алтын стеналарны күрергә була. Бу су катламы астындагы хәзинә балкышын хәтерләтә, әйтерсең лә, театр үзе хәзинә – Кабан күле хәзинәсе...»*

**Фоторәсемнәр авторның шәхси архивыннан**



# ТИМЕРГӘ жан җылысы өрүче ОСТАЛАР...

**Рәшит Галләм,**
*тарихчы*

**Минзәлә шәһәрендә эшмәкәр Игорь Цветков җитәкләгән «Сәнгатьле чүкү» шәхси предприятиесен белмәгән кешеләр сирәктер, мөгаен. Металл төзелеш конструкцияләре һәм эшләнмәләре җитештерүче әлеге цех инде 2011 елдан бирле уңышлы эшләп килә. Шунысы кызык: бу эшне булдыру уе башта Игорь Витальевичның әтисе күңелендә туа. Улы армия сафларыннан кайтуга, ул аңа эретеп ябыштыру эшенә тотынып карарга тәкъдим итә. Нәкъ менә шуннан башланып китә дә инде Игорьның эшмәкәрлек өлкәсендәге тәүге адымнары. Күңелендә иҗат уты, эш дәрте кабынган егет башта бизнес-план төзеп, шәһәр администрациясенә мөрәҗәгать итә. Администрация эш планын хуплап, субсидия бүлеп бирү белән, Игорь Витальевич станоклар, эш өчен кирәкле башка җиһазлар кайтарта.**



Бүгенге көндә предприятие гөрләп эшләп килә. Үз эшенең осталары булган 9 кешедән (5 эретеп ябыштыручы һәм 4 монтажлаучы) торган бу дус-тату коллектив тимердән сокланып карап туймаслык матур эшләнмәләр – сырлы-бизәкле капка-коймалар, рәшәткәләр, әвеслекләр, тәрәзә читлекләре, болдыр-баскыч култыксалары, җәйге беседкалар, бакча эскәмияләре, өстәлләр, гөл киштәләре, мангаллар ясый. Хәзерге заманның төрле уңайлы станоклары, заманча җиһазлары бу эшләрне сыйфатлы да, тиз дә итеп башкарырга мөмкинлек бирсә дә, гап-гади металлдан сәнгать әсәре булырдай мондый матурлык тудырыр өчен күңелең белән нәфислекне тоя-сизә белергә, салкын тимергә җан җылыңны да өреп, зур тырышлык куярга, кыскасы, үз эшеңнең чын остасы булырга кирәк.

Җитештерү процессының гаять төгәл, төзек, тәртипле бер көйгә салынган булуы, осталарның югары һөнәри дәрәҗәләре тимердән



коеп ясалган рояль, автомобиль, велосипед кебек гаҗәеп эшләнмәләр дә ясарга мөмкинлек бирә бу предприятиедә. Шундый уникаль экспонатлар Минзәләнең үзәк сәүдә аллеясы булган «Гостиный двор»ын да бизәп, аңа кабатланмас бер колорит биреп тора.

XX гасыр башында салынган Минзәлә тимер юл күперенә 2022 елда урнаштырылган, эпохасына туры китереп, стильләштерелеп ясалган, үзенең чын рәвешеннән аерып булмаслык паровоз да – үзе бер сәнгать!

Ул күпернең тарихы да игътибарга лаек. XX йөз башында патша Россиясендә, тимер юллар төзү планы буенча, Бөгелмәдән губерна шәһәре булган Уфага бара торган тимер юл тармагы Минзәлә аша узарга тиеш була. Ләкин 1914 елда башланган Беренче бөтендөнья сугышы бу планны гамәлгә ашырырга ирек бирми – Минзәлә елгасы аша тимер күпер генә торгызырга өлгерәләр. Халык телендә «Екатерина күпере» дип аталган бу күпер хәзер Минзәлә шәһәренең тарихи истәлекләреннән санала, аның символы булып тора.





Бүген бу паровозлы күпердә шәһәр халкының олысы-кечесе, туристлар, балалар рәхәтләнеп ял итә, балык тота. Якында гына җәйләрен минзәләлеләрнең яратып су коена торган урыны – заманча корылган комлы пляж да бар.

Тимердән коеп ясалган әйберләрнең популярлыгы елдан-ел арта бара. Игорь Витальевич Цветковның «Сәнгатьле чүкү» шәхси предприятиесен Минзәләдә генә түгел, тирә-якта да яхшы беләләр. Предприятие осталары җитештергән экспонатларны Мамадыш, Яр Чаллы, Түбән Кама шәһәрләрендә дә күрергә мөмкин. Ә 2022 елда исә алар герой-шәһәр Волгоградтан да заказ алганнар хәтта!

Моннан тыш, предприятие җиңел корыла торган металл конструкцияләр ясау белән дә шөгыльләнә. Мисалга Минзәләнең үзендә И.В. Цветковның шәхси предприятиесе урнашкан «Феникс» офислар бинасын китерергә була. Предприятие шулай ук төрле формадагы, конфигурациядәге ангарлар да төзи.

Минзәлә районының Иске Мазино, Тупач, Хуҗәмәт авылларындагы чишмәләрне төзекләндерүгә дә күп көч керткәннәр предприятие осталары.

Шулай итеп, Минзәләнең тимер кою осталары үзләренең иҗади хезмәтләре белән тирә-якны матурлыйлар, дөньяга ямь өстиләр.

Без зур үзгәрешләр, технология үсеше чорында яшибез. Ә борынгыдан килгән һөнәр-кәсепләребез исә, кызганыч, әкренләп онытыла, югала бара. Ә менә тимер чүкү, тимер кою һөнәре, киресенчә, югалмый, популярлаша гына. Хәзерге заманда бу шөгыль торак йорт һәм офислар, бакча һәм парклар дизайны белән үрелеп үсә. Бүген шәһәр яны, дача бистәләрен тимердән койган капка-коймаларсыз күз алдына китереп тә булмый. Шуңа да бу һөнәр беркайчан онытылмас, югалмас дигән өмет бар. Игорь Витальевичның да гомерен багышлаган эшенең дәвамлы булачагына, ә Минзәлә осталарының хезмәт җимешләре Татарстанда гына түгел, читтә дә танылып, тиешенчә бәяләнәчәгенә ышанычы зур.

**Фоторәсемнәр авторның шәхси архивыннан**





# Дәһшәтле чорның ышанычлы юлдашлары

**Лилия Мөхәмmәтҗанова,**
*филология фәннәре докторы, доцент, Татарстан Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының баш фәнни хезмәткәре*



**Халкыбыз күңелен тетрәндерерлек вакыйгалар яшәеш-көнкүрештә әледән-әле килеп чыга тора, аларның кайтавазы халык иҗаты әсәрләре булып формалаша. 1941-1945 елгы Бөек Ватан сугышы да – халык тормышында җуелмас тирән эз калдырган тарихи вакыйгаларның берсе.**

Халык Бөек Ватан сугышын тормышының астын-өскә әйләндереп аткан вакыйга буларак кабул итә. Сугыш афәте кагылмаган бер генә йорт та, бер генә гаилә дә калмый. Кемнеңдер кемедер фронтка китеп, дошманга каршы кулына корал алып көрәшә башлый, кемдер туган җирен ташлап каядыр күченергә мәҗбүр була, ә күпләр өчен фронтны бер генә минутка да күздән ычкындырмаган авыр тыл хезмәте башлана, моңа сугышта газизләрен югалту ачысы да өстәлә. Кеше тормышына бәреп килеп кергән бу кискен үзгәрешләр татар халык иҗаты үсеше өчен өр-яңа шартлар тууга да сәбәпче була. Сугыш вакытындагы тормышның авырлыгы халыкның күңел төпкелендә элек-электән яткан тирән хисләрен уята. Бу исә тарих тузаны баскан үрнәкләрнең кабат тергезелүенә китерә, шулай ук татар рухи мирасын яңа үрнәкләргә баета.

## Лирик җырларда – җиңүгә ышаныч

Бөек Ватан сугышы чорында татар халык иҗаты жанрларыннан җырлар аеруча активлаша. Татар җырларында халкыбызның күңел түрендә йөри торган уй-теләкләре, борчу-мәшәкатьләре чагылыш тапкан, әлеге закончалык сугыш чоры лирик иҗатына да кагыла. Тормыш шартлары никадәр генә авыр булуга карамастан, халык җырлары яшәвен дәвам иткән, халыкның күңелен юаткан, кешеләрне бирешмәскә өндәгән.

Вакыйгасына күрә, сугыш елларында туган илгә басып кергән дошман явына нәфрәт, үз ватаныңа мәхәббәт, аның азатлыгы өчен көрәш идеяләре белән сугарылган лирик иҗат алгы планга чыга. Лирик җырлар татар халык иҗатында гомер-гомергә аерым зур урын биләгән. Бөек Ватан сугышы вакыйгалары уңаеннан алар өр-яңа яңгыраш ала, халык тормышында үзенә бер функция үти башлыйлар.

Лирик озын җырлар – күп строфалы, сюжетлы, катлаулы синтетик музыкаль-поэтик лирик иҗат. Лирик кыска җырлар озын көйле җырлардан шигъри төзелеше ягыннан, нинди көйгә башкарылулары белән, кайсы теманы колачлавы җәһәтеннән һәм башка яклары

белән аерылып торалар. Җырларның озын көйләләрен дә, кыска дүртьюллыктан гыйбарәт булганнарын да һичшиксез берләштерә торган сыйфат – ул әлбәттә, лирика. Сугыш чорында популярлык алган лирик иҗатта да шәхси тойгы аша кемгә яки нәрсәгә дә булса субъектив мөнәсәбәт белдерелә, җырлаучының хәле-халәте, кәефе гәүдәләнеш таба. Лиризм хис-кичерешләрдәге, кәеф-халәттәге тойгыны, эмоциональ башлангычтагы нәзек нечкәлекләрне аңлатып бирә; ул эмоциональлек, шигъри дулкынлану, күңелне айкау характерына ия. Бөек Ватан сугышы чорында лирик поэзия, хис-кичерешләрне чагылдыра торган иҗат буларак, халыкның килеп туган кыенлыкларга мөнәсәбәтен билгели, күңел бушату чарасы булып та хезмәт итә.

Мәсәлән, 1960 елда Татарстан радиосы фонотекасыннан күчереп алынган «Актаныш басмалары» исеме белән мәгълүм халык җыры Бөек Ватан сугышы вакыйгалары уңаеннан популярлашкан дип уйларга тулы нигез бар. Җыр-

**Татар җырларында халкыбызның күңел түрендә йөри торган уй-теләкләре, борчу-мәшәкатьләре чагылыш тапкан, әлеге закончалык сугыш чоры лирик иҗатына да кагыла. Тормыш шартлары никадәр генә авыр булуга карамастан, халык җырлары яшәвен дәвам иткән, халыкның күңелен юаткан, кешеләрне бирешмәскә өндәгән.**

да туган илгә генә хас атрибутлар – Агыйдел суы, Актаныш басмалары, кызларның үргән чәчендә җилфердәүче тасмалар, апрельдә кузгала торган бозлар һәм башкалар телгә алына, аларның газизлеге ассызыклана, шулар хакына туган якка җиңеп кайткан батырлар мактала:

Апрель җитми агып бетми
Агыйделнең бозлары;
Мул уңышлар яулап алыр,
Егетләре, кызлары.



**Халидә Гатина. Актаныш, Әмәкәй. 1948 ел**



**Илбарис Надиров, җырлар яздырган мизгелдә**

Каян барсаң, шуннан туры
Актанышның юллары;
Дошманнарны җиңеп кайтты,
Безнең район уллары.

Мондый төр җырлар арасында нигездә профессионаллар иҗат итеп, соңыннан халыклашып киткән җырлар күп. «Сагыну», «Юксыну» кебек җырлар моңа мисал була ала. Сугыш чоры җырларының әлеге төркемендә киләчәк җиңүгә тулы ышаныч, совет илен намус белән саклау-яклау, һәм, бәлки, халык иҗаты әсәрләренә бик үк хас булмаган «кызыл» идеяләр дә бар. Хәлбуки мондый җырлар халык репертуарында булган һәм алар әле безнең көннәрдә дә очрап куялар. Бу төр җырлар һәркайда – авылда һәм шәһәрдә, яшьләр һәм өлкәннәр арасында, үзешчән сәнгать түгәрәкләрендә, фронтовиклар каршында яңгырый торган булган. Идеологик халык җырларының киң таралып популярлашуына үз вакытында аларның профессиональ артистлар башкаруында бик еш кабатланып торуы да йогынты ясаган. Композицион төзелешләре, сәнгатьчә эшләнешләре ягыннан алар милли мирас җырлары рәтендә каралалар. Бөек Ватан сугышына бәйләп карала торган мондый җырлар – чорның идеологик фикерләре белән тыгыз бәйләнеш торган, патриотик хисләрне алга куйган иҗат.

## Минем иркәм – бригадирка

Сугыш чоры җырларында гражданлык лирикасына зур урын бирелгән, авырлыкларга баш имәү пропагандаланган, көр күңеллелек һәм батырлыкка өндәү хупланган. Бөек Ватан сугышы елларында яшьләр арасындагы мөнәсәбәтләрне яктырткан җырларда, мәсәлән, егетнең яисә кызның эшчән булуы, хезмәт сөюе еш кына телгә алына, мәхәббәт хисләре эшчәнлек аша яктыртыла:

Минем иркәм бригадирка,
Күкрәгендә медале;
Казанда да, Мәскәүдә дә
Белмәгәннәр юк аны.
Минем иркәм иртә тора,
Таң йолдызы шикелле;
Үзе уңган, үзе булган,
Үзе шундый сөйкемле. *(«Минем иркәм»).*

Бу җыр татар халык җырлары фондына 1953 елда Татарстанның Әлки районы Үргагар авылында Роза Арслановадан (1938 елда туган) язып алып кертелгән. Җырда кешенең иҗтимагый асылын билгеләгән төп сыйфат буларак аның хезмәткә мөнәсәбәте саналуы ассызыклануда заманның кырыс шартлары төп рольне уйнаган. Җиңү хакына көрәшнең ул елларда тылда да җиңелләрдән булмавын шушындый халык җырлары аша тоемларга мөмкин. Тылда хезмәт куючы батырларның асылда хатын-кызлар булганлыгы мәгълүм. Лирик җырда нәкъ менә сөйкемле сылу кызның физик хезмәттәге уңышларын мактап җырлау сугыш чоры рухын тулы чагылдыра.

## Сугыш чорында мәхәббәт лирикасы

Сугыш афәте килгәндә дә җырлап күңел бушаткан халык үз репертуарына заман рухына аваздаш булган әсәрләрне күпләп керткән. Каһарманлык, ватанпарвәрлек белән сугарылган җырлар янәшәсендә тирән кайгы, хәсрәт, аерылу, сагыну, ярату хисләре өстенлек алган җырлар да бу чор халык иҗатының төп колоритын билгели. Илне сакларга фронтка киткән сугышчы яисә аны озатып калган яры сөйгәнен уйлап сагышлана, кабат күрешүгә өметләнә:

Кама суы сиңа таныш түгел,
Ялгыз гына төшеп буйлама;
Ара ерак, хатлар озак йөри,
Оныткандыр диеп уйлама.
Буйларында бик күп йөресәм дә,
Һич туялмыйм ямьле Камадан;
Мәхәббәтем Кама кебек тирән,
Очрашырбыз әле яңадан.

«Кама буе» исемле бу җыр Татарстанның Кайбыч районы Борындык авылында Сәрия



**Хәмит Ярми**

Ногмановадан (1928 елда туган) 1955 елда язып алынган.

Татарстанның Ширәмәт районы Ширәмәт авылында Сания Гатауллинадан 1961 елда язып алынган «Сарман» җыры да язмышларны бутарга, авырлыклар китерергә сәләтле сугышның барлык ачысын тойган гади халыкка хас самими хисләрне чагылдыра:

Сарман буйларында салкын җилләр,
Туңам, иркәм, туңам, туның бир;
Аерылабыз, иркәм, аерылабыз,
Саубуллашыйк инде, кулың бир.

Сарман буйларын мин буйладым,
Буйлаганда сине дә уйладым.
Киткән чакларыңда кул бирмәдем,
Тагын кайтырсың дип уйладым.

Сарман сулары ла салкын сулы,
Сулары ла аның кар сулы;
Салкын сулар эчсәм дә басылмый,
Йөрәккәем бигрәк ярсулы.

Сарман буйларында каенлык бар,
Каен арасында ташлар бар;
Онытыла диеп әйтсәләр дә,
Онытылмый шул ул сөйгән яр.

**Жырда кешенең иҗтимагый асылын билгеләгән төп сыйфат буларак аның хезмәткә мөнәсәбәте саналуы ассызыклануда заманның кырыс шартлары төп рольне уйнаган. Җиңү хакына көрәшнең ул елларда тылда да җиңелләрдән булмавын шушындый халык җырлары аша тоемларга мөмкин.**

Бу җырның 1955 елда Татарстанның Кайбыч районы Борындык авылында Сәрия Әскәровадан (1940 елда туган), 1969 елда Омск өлкәсенең Большеречье районы Уба авылында Маһирә Хәлиловадан (1938 елда туган) язып алынган вариантлары да булу җырның үз чорында шактый таралганлыгын күрсәтә.

## Пешәр солдат ашлары...

Бу чорда фронттагы солдатлар тарафыннан иҗат ителгән җырларны да Бөек Ватан сугышы чорына караган лирик иҗатның аерым төркеме итеп билгеләү дөрес булыр. «Илне сагыну җыры», мәсәлән, 1958 елда Мордва Республикасының Беднодемьянск районы Таракан авылында Абдулла Үтәмешевтән (1899 елда туган) язып алынган:

Кырда карчыгалар кагынып йөри,
Коймасларымы кырлар тарысын?
Карчыга,
Күрешә алмыйча күңелем талчыга.
Илең сагынасыңмы дип сорыйсың,
Күрмисеңме йөземнең сарысын?
Карчыга,
Күрешә алмыйча күңелем талчыга.
Кычкырмачы, кәккүк, син кычкырма,
Әчкенәемне минем пошырма!
Кәккүгем,
Чит җирләрдә үтә яшьлегем!
Ил генәмә кайтып, сөйгән белән
Бер кавышыр көннәр булырмы?
Кәккүгем,
Чит җирләрдә үтә яшьлегем!

Бу чорда Бөек Ватан сугышына кадәр тарихта билгеле сугышлар уңаеннан чыгарылган җырлар да сугышчылар арасында кабат популярлаша. Мәсәлән, «Окоп көе» дигән исем белән билгеле җыр 1941 елда А. Ключаревның «Татар халык көйләре» җыентыгында басыла. (1 китап, 1941, 94 б.). Искәрмәсенә караганда, бу әсәр рус-япон сугышы чорында ук мәгълүм булган. А. Ключарев җыентыгында нотасы белән бирелгән строфа шундый:

Солдатский ремень белән
Будылар билләремне шул.
Йөгереп китәрдәй булам ла,
Чит илләрдә үтә гомерем,
Сагындым илләремне шул.

Бу җыр Ә. Абдуллин «Көзге ачы җилләрдә» исеме белән 1960 елда ТФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты Мирасханәсенә тапшырган җырлар дәфтәрендә дә урын алган. (ФФ, 1960, колл. 1, п. 34а, сак. бер. 565а).

«Солдат җыры» дип аталган түбәндәге җыр исә 1970 елда Төмән өлкәсе Түбән Тауда районы Байкал (Бохара) авылында Сәрби Сабитовадан (1895 елда туган) магнитофон тасмасына язып алынган (язып алучы һәм нотага салучы – И. Кадыйров). XX йөзнең җитмешенче елларында да җырланганын исәпкә алганда, Бөек Ватан сугышыннан соң аның әле шактый популяр җырлар рәтендә булуы аңлашыла:

Чуен чүлмәк, аузы тар ла,
Пешәр солдат ашлары ла;
Кош-корт очып җитмәс җиргә,
Китә солдат башлары ла.

Таш казарма буйларына
Мылтыгымны сөядем;
Туган-үскән илләремә
Кайчан кайтыр сөягем?

Солдат итеп алдылар,
Билемә каеш салдылар;
Минем белән барган дуслар
Яраусызга калдылар.

Бу җыр – борынгы солдат җыры, аның элекке чорларда патша армиясендә татарлар язмышын тасвирлаган үрнәкләрдән булу ихтималы зур. Күрәсең, җырдагы актуаль

вакыйгалар уңаеннан Бөек Ватан сугышы чорында ул кабат «яңарган».

## Ил яшәве – җыр белән

Сугыш чоры җырлары – батырлыкка һәм матурлыкка мәдхия. Бөек Ватан сугышы чорында «Сарман буйлары», «Кошлар кебек», «Сугышчы җыры», «Арча», «Су буйлап», «Өй артында шомыртым», «Рамай» кебек үлемсез җырлар халыкта бик нык популярлык казана, радио аша еш яңгыраулары да бу җырларның халык хәтеренә ныграк уелуын, телдән-телгә күчеп, халык вәкилләре, үзешчәннәр тарафыннан җырлануын тәэмин итә.

1941-1945 еллардагы сугыш чоры җырлары дисәк тә, мондый иҗат шактый киң вакыт аралыгын алып тора. Аларга карата нәкъ менә сугыш вакыйгаларына гына бәйле барлыкка килгән һәм сугыш вакытында гына җырланган дигән катгый чикләрне куеп та булмый. Җырларның кайберләре – Бөек Ватан сугышына кадәр үк билгеле һәм хәтта әле бүген дә популярлыгын югалтмаган әсәрләр. Алар – тылда да, фронтта да халык белән бергә булган, кыенлыклар алдында югалып калмаска булышкан, сугыш елларында халыкка рухи көч өстәп торган җәүһәрләр.

Бөек Ватан сугышы чорына хас лирик озын җырларның һәркайсы эчтәлек ягыннан бай мәгънәле, образлары күпкырлы булуны танымый мөмкин түгел. Татар халкының тарихи үткәнен һәм этнографик үзенчәлекләрен, иҗтимагый тормышын, гаилә-көнкүреш мөнәсәбәтләрен һәм үз җире өчен көрәшкә омтылу, якыннарын дошманнардан азат итү идеяләрен алга сөреп, батырлыкны лирика аша сурәтләгән юлларның әһәмияте ил, ватан өчен хәлиткеч заманда тагын да арта. Бу җырларда татар кешесенә хас хисләр, кичерешләр, чор вакыйгалары үз эзен салган тойгыларны, җиңүгә булган зур өметне табарга мөмкин.

Җыр поэзиясенең сугыш вакытында аеруча бай булуы, беренчедән, аның борынгы шигъри традицияләргә үк барып тоташкан булуыннан килә, икенчедән, шагыйрьләр һәм композиторлар иҗатының иң уңышлы



**Халидә Гатина, Зәйнәп Максудова, язучы Нурихан Фәттах. Актаныш. 1948 ел**

үрнәкләренең халыклашып торуы, профессионал җырчыларның халык әсәрләрен матбугат чаралары аша яңгыратулары да моңа йогынты ясый. Халык өчен авыр вакытта да җырлар онытылмаган, димәк, җырның поэтик бизәкләре дә яңа заманга күчкән. Элек-электән җырлана килгән әсәрләр яңа этапта әнә шулай киләчәккә хәрәкәт иткәннәр. Сугыш чорында җырланган җырларның һәрберсе мондый нәтиҗәгә лаек дип булмый, әлбәттә, әмма аларның күбесе асылда нәкъ менә вакыт сынавын үтеп, бүгенге көнгә килеп җитә алган. Җырлар төрле ситуациядә җиңел генә хәтергә килә, кешеләрнең күңел халәтенә бәйле еш башкарылалар. Шуңа алар дәһшәтле елларда да халыкның аерылмас юлдашы булганнар.

**Рәсемнәрдә:**
**ТФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты галимнәре Бөек Ватан сугышыннан соң кабат уздырыла башлаган фәнни экспедицияләрдә информантлар белән. 1948 ел**

**Фоторәсемнәр ТӘһСИ архивыннан**

# Хәрби хезмәткә озату

## (Фольклор күренеш. «Хәзинә» фольклор коллективы мисалында)

**Ләйлә Хәкимова,**
*Арча районы Мәдәният йорты сәнгать җитәкчесе*

**Катнашалар:**

Инсаф, Илназ, Алмаз – *авыл егетләре;*

Гомәр – *армиягә китүче егет;*

Зөлфия апа белән Фәнис абый – *Гомәрнең әти-әнисе;*

Ләйлә, Фәрдия, Зөлфия, Гүзәл – *авыл кызлары;*

Асылъяр – *армиягә китүче егетнең сөйгән кызы.*

*(Егетләр-кызлар сәхнәгә җырлашып керәләр.)*

Без үскәндә үскән идек,
Тал тамырлары кебек.
Үсеп җиткәч таралыштык,
Кош балалары кебек.
Китәм дисең, китәм дисең,
Китәм, дисең кайларга?
Ниләргә сабыр итмисең
Тагын өч-дүрт айларга?

*(Гомәр җырлый.)*

Военкомат идәннәрен
Таптамам дигән идем.
Туып үскән авылымны
Ташламам дигән идем.

**Инсаф:**

Армиягә чакыру кәгазе килгәч, военкомат идәннәрен таптамый булмый шул. Я, ярый (Гомәрнең җилкәсеннән кагып), бер ел хәзер үтә дә китә ул, Гомәр. Сизми дә калырсың әле.

**Илназ:**

«Армия – ул тормыш мәктәбе, аннан чын егет булып кайтасың», – ди әти. Әнә, безнең авылдан Фәрит, Әхмәт абыйлар ничек көрәеп кайттылар.

**Алмаз:**

Армиядә хезмәт итеп кайту – зур дәрәҗә ул, Гомәр, ә бармый калу оят. Без, авылдашлар, синең белән горурланабыз. Хәрби бурычыңны намус белән үтә, йөзебезгә кызыллык китермә.

**Гомәр:**

Дөрес әйтәсез. Рәхмәт сезгә, егетләр!





**Зөлфия:**

Тәмам ялыктырып бетердегез инде Гомәрне. Төшеп калган егет түгел лә, үзе дә бик яхшы белер ни эшләргә кирәген.

**Алмаз:**

Соң, өлкәннәр үгет-нәсыйхәт бирергә тиеш бит инде. Аның йоласы шундый. Хәрби хезмәткә дә йоласына туры китереп озатырга кирәк.

**Гүзәл:**

Ай, йола дигәннән... Бөтенләй онытып җибәргәнбез. Кайтып җиткәч, миңа хәбәр итәрсез, дигән иде Зөлфия апа. Гомәрне, әнисе күңел җылысын кушып пешергән икмәкне каптырмыйча, озатырга ярамый.

**Барысы бергә:**

Шулай шул. Зөлфия апа! Зөлфия апа! Чык әле бирегә. Без кайтып җиттек.

*(Гомәрнең әти-әнисе чыга.)*

**Зөлфия апа:**

Әтисе, әйдә, кызула. Кайтып та җиттегезме, балалар? Тавышыгызны ишеттек. Бик вакытлы кайттыгыз. Менә, икмәгем дә пешеп чыкты. Бик уңды, күпереп пеште. Кил әле, Гомәр улым. Солдат хезмәтенә озатуның иң олы йоласы – икмәк каптыру. Читкә китүченең өйдә җыясы ризыгы калса, ул, һичшиксез, кире әйләнеп кайтырга тиеш дигән ышану яши. Яле, яле (Гомәр икмәкне каба). Менә шулай улым, ә калган икмәкне өебезнең аулак урынына куярбыз, ул син кайтуны теләп торыр. Исән-сау әйләнеп кайтып, мин әзерләгән ризыклардан әле озак еллар авыз итәргә язсын.

**Гомәр:**

Рәхмәт, әнкәй. Син пешергән икмәк тәмен чит җирләрдә булганда сагынырмын әле, бик нык сагынырмын. Кайткач үземә насыйп ризык булсын!



**Барысы бергә:**

Амин! Амин шулай булсын!

**Фәнис абый:**

Нәселебездә барысы да армия хезмәтен үтте, улым. Бабаең Бөек Ватан, мин Әфган сугышында булдык. Абыйларың да Ватан алдында үзләренең хәрби бурычларын үтәделәр. Ватанны саклау – һәр ир-егетнең изге бурычы. Кадак даганы саклый, дага юрганы саклый, юрга батырны саклый, батыр Ватанны саклый, ди халык. Ә халык әйтсә, хак әйтә. Армиядә кеше ныгып, авырлыкларга бирешмәскә өйрәнеп, нык ихтыярлы булып кайта.

**Гомәр:**

Әткәй! Мин сезнең, нәселебезнең, авылдашларның йөзенә кызыллык китермәм.

**Зөлфия апа:**

Рәхмәт, балам, рәхмәт! Менә шушы кульяулыкны да ал әле. Борынгыдан калган гадәт буенча, сиңа туган җир туфрагы салынган кульяулык тапшырам. Туган йортка туган җир туфрагы тартып кайтарсын өчен шулай эшләнә. Әлеге туфрак сиңа көч-куәт өстәп торсын.

**Гомәр:**

Рәхмәт яусын, әти-әни! Сезнең яратуыгыз мине саклап йөртер.

**Фәнис абый:**

Без барлык йолаларны үтәдек. Яшьләрнеке яшьләрчә булсын, әнисе. Үзләрен генә калдырыйк.

**Фәрдия:**

Егетләр, кызлар! Бигрәк моңсу булып китте. Әйдәгез, бергә җыелган чакларны сагынып искә алырлык булсын әле. Үзебезнең яраткан җырлы-биюле уеннарны уйныйк.

*(Яшьләр җырлы-биюле уеннар уйныйлар.)*

**Ләйлә:**

Гомәр, авылыбызда синең кебек курайда оста уйнаучы юк. Шул моңнарны сагынырбыз инде. Әйдә, барыбыз да бергә җыелганда бер уйнап ал әле.

*(Гомәр курайда уйный.)*

**Зөлфия:**

Яшьлекнең иң матур мизгелләре шушыдыр инде ул. Безнең тавышка күрше авыллар да төшми калмас.

**Илназ:**

Без урамнан үткән чакта ачуланмасын кеше,<br>Ир баласы булган кеше күрми калмый<br>бу эшне.<br>Без урамнан үткән чакта ачуланма, агайлар,<br>Ачуланмагыз, агайлар, без китәсе малайлар.<br>Урам буе коймагызга сандугач кунар әле,<br>Шаулап торган урамыгыз, без киткәч<br>тынар әле.

**Гомәр:**

Асылъяр, мин сине бүген танымыйм. Ут чәчеп торган Асылъярым кая киткән минем?

**Асылъяр:**

Әй, Гомәр. Ут чәчеп торырлыкмени монда. Сине сагынуга ничек түзәрмен икән? Бер ел бит ул, бер ел.

**Гомәр:**

Юкка борчылма әле син, җаным. Бер ел уза да китә ул. Хатлар алышырбыз.

**Асылъяр:**

Хатлар гына сине алыштыра алмас шул.

**Гомәр:**

Син мине көт кенә. Көтәрсең бит?

**Асылъяр:**

Әлбәттә, көтәрмен, җаным, көтәрмен.



**Гомәр:**

Вәгъдәме?

**Асылъяр:**

Вәгъдә, җаным, вәгъдә. Менә, сиңа дип атап, күңел җылымны кушып, кулъяулык чиктем. Саклап йөрт, яме.

**Инсаф:**

Без монда артык, бугай. Кузгала торыйк мәллә, егетләр-кызлар?

**Гомәр:**

Тагын бер-икене җырлыйк инде, егетләр-кызлар?

*(Егетләр-кызлар кара-каршы җырлашалар.)*

**Кызлар:**

Минем иркәм армиядә,
Сагыз кайнатам дигән.
Кайткан чакта бер чәйнәрлек
Сагыз апкайтам дигән.

**Егетләр:**

Стенада сәгать йөри,
Саный минут исәбен.
Бу минутта нишли икән,
Минем бәгырь кисәгем?

**Кызлар:**

Алларын алга манам,
Гөлләрен гөлгә манам.
Иркәм китте еракларга,
Сагыну утында янам.

**Егетләр:**

Китәм диден, читкә киттең
Чит иде теләкләрең.
Инде хәзер чит илләрдә
Өзелер үзәкләрең.

**Гомәр:**

Егетләр-кызлар, авыл урамнарын да бер җырлап әйләник әле. Авыл башындагы агачка кульяулык та бәйлисе бар.

**Инсаф:**

Солдатка алынучы егеткә бәйле тагын мондый гадәт тә бар: егетне ике дусты иңбашыннан тотып, өй ишегеннән арты белән алып чыгалар. Болай эшләгәндә егет туган йортына йөзе белән әйләнеп кайтачак. Әйдә, киттек.

*(Җырлашып чыгып китәләр.)*

Без авылдан чыккан чакта,
Күтәрелде томаннар.
Яз кайтмасак, көз кайтырбыз,
Сау булыгыз, туганнар!

**Фоторәсемнәр авторның шәхси архивыннан**

# ӘФСЕННӘР – дөньялык белән аралашу теле

**Галимҗан Гыйльманов,**
*язучы, әдәбият белгече*



**Әфсеннәр (русча: заклинания) – мифологиянең иң катлаулы жанры. Чөнки аның чикләрен, кысаларын билгеләү искиткеч авыр, хәтта мөмкин хәл түгел. Ул сихер, тылсым, ырым, им-том текстларының барысында да бар. Хәтта арбау, келәү кебек мәҗүси догаларда да еш кына хәлиткеч компонент буларак катнаширга мөмкин. Кыскасы, әфсеннәр – магик көчкә ия булган әйтем-формулалар. Борынгылар әфсеннәр ярдәмендә башкаларга тәэсир итеп була, теләгән халәткә ирешеп була, хәтта табигать көчләрен тәңреләр, рухлар, иянәр аша җанландырып, хәрәкәткә китереп була дип санаганнар.**

А.Н. Веселовский фикеренчә, әфсеннәр – күктә илаһи көчләр тарафыннан башкарылган эшләрне җирдә кешенең яшәеш мохите кысаларында кабатлау гына. Бу очракта әфсеннәр мифларга кушымта яисә иллюстрация, еш кына «төзү материалы» буларак та карала алалар. Аларны «мифларның теле» дип тә әйтәләр.

Бүген без әфсеннәрне татар мифологик (димәк, рухи, милли, мәдәни) мирасының бер берәмлеге итеп кенә карыйбыз, өйрәнәбез... Ул инде элеккеге актив позициясен югалткан. Әмма халык тормышында, үзаңында, рухиятендә һаман бар. Әйтик, каршыңда уйнап йөргән бала егылса, шундук, әби-бабайлардан отып калган әфсен имләвен әйтергә тотынабыз:

Име-томы шул булсын,
Җил белән килсәң – җилеп кит,
Очык белән килсәң – очып кит!
Тфү! Тфү! Тфү!

Елга-күл буенда балык тотып утырган балалар телендә дә бар әле ул әфсен формулалары. Әнә алар, үзләре дә аңлап бетермичә, буыннан буынга, телдән телгә күчеп килгән сүзләрне такмаклыйлар:

Төкереп салдым,
Сикереп кап!
Яр башында ялтырап ят!
Ялтырамасаң,
Калтырап кат!

Әлбәттә, болар – халык хәтеренә төшеп калган җиңелчә, көндәлек әфсеннәр. Ә бит аларның бик җитдиләре дә була. Гомумән магик формулаларга, мәҗүси догаларга, әфсен-төфсенгә, ырым, имләү текстларына уйнап кына, такмак итеп кенә карарга ярамый. Аларда йөзәр, меңәр еллар буе практик йолалар белән сыналган тотрыклы формулалар бар, димәк, шаукым бар, кешенең зиһененә тәэсир итү ысуллары, генетик дәрәҗәдә генә аңларга мөмкин булган символлар, кодлар бар...

Әфсеннәр ике «канатлы»: аның бер канаты – сихер, икенче канаты – тылсым. Шуңа күрә

дә әфсеннәрне бары тик уңай яктан гына яисә тискәре яктан гына бәяләп булмый. Кайсы як көчлерәк – шунысы мөһим. Сихерче өчен сихерләү, кешенең аң-зиһененә тәэсир итеп, еш кына «кара сихер» кулланып, теләгәнен эшләү мөһим булса, имче, тылсымчы өчен өшкерү, дәвалау, кешенең күңел халәтен яхшырту, гомумән, изге гамәл кылу – төп максат. Димәк, «сихерләү» һәм «өшкерү» дигән төшенчәләр бар. Икесенең дә үз максатлары, үз әфсеннәре бар.

Сихер турында берничә сүз. Сихер ул – төрле әфсен текстлары, сихерләү йолалары аша (әйтик, төеннәр бәйләү, энәләр кадау һәм башкалар) кешенең акылына, зиһененә, җанына-тәненә һәм холкына-тәртибенә тискәре йогынты ясау. Чынлыкта ул – җеннәргә, шайтаннарга, түбән рухларга мөрәҗәгать итүче кеше, алар ихтыяры белән яман гамәлләр кылучы зат. Күпчелек очракта сихер йолалары «изгелек эшләү» сылтавы белән башкарыла, шунысы куркыныч та. Шул да мәгълүм булсын: Коръән әфсеннәргә, әфсеннәр аша кергән сихергә гомумән каршы. «Бәкарә» (Сыер) сүрәсенең 102нче аятендә турыдан-туры әйтелгән: «Сихерне өйрәтеп һәм аның белән эш кылып, кяфер булмагыз!» – диелгән. Динебез буенча, иң авыр 7 гөнаһның өченчесе сихер икәнен дә онытырга тиеш түгелбез.

Сихернең тарихы Бабилдагы Һарут белән Марут исемле фәрештәләргә барып тоташа. Сихер нәкъ менә аларга иңдерелгән була. Ә алар ярамаган эш эшлиләр: сихерне кешеләргә өйрәтәләр. Шуннан башлана да инде... Мөселман динендә әфсеннәр (Рукъя), әфсенле бөтиләр (Тамаим) – сөйдергеч әфсеннәр (Тиваля) – ширек (күп аллага ышану, мәҗүсилек) дип санала. Ниндидер сихри әфсеннәре булган әйберләрне муенга, киемгә һәм беләккә тагу ислам динендә рөхсәт ителми. Мондый гамәлләр кешене мәҗүсилеккә алып керергә мөмкин...

Ләкин милли традицияләрне, милли һәм әхлакый мирасны, ата-бабаларның яшәү кодексын кая куясың?! Әфсенле тормыш, сихри гамәлләр, ышанулар – аларның яшәү рәвеше булган бит! Алар, иртән уянып, уң аяк белән идәнгә басканнан алып, төнгелеккә йокыга талганчы ниндидер әфсеннәр пышылдаганнар... Авырсалар – имләп өшкергәннәр, егылсалар – тәкеренеп бозымнан сакланганнар, табигатькә чыксалар – аларның ияләрен, рухларын мәҗүси әфсеннәр, догалар, йола гамәлләре, сихер-тылсым әйберләре, ризыклар белән бәхилләткәннәр... Болар барысы да безнең генетик хәтердә яши, һәм без аларны онытырга, алардан баш тартырга тиеш түгел. Юкса без үзебезнең милли асылыбызны югалтачакбыз, милли яшәеш программасында хаталар башланачак...

Бу очракта бер генә юл кала: милли йолаларыбызны, мәҗүсилектән үк килүче халык традицияләрен бүгенге хакыйкый динебезнең йолалары, традицияләре, гомумән, ислам тәгълиматы белән килештереп яшәргә тиешбез. Аның ачык мисалы – Сабантуй бәйрәме. Мәҗүси йола буларак туган бу бәйрәмебез хәзер ислам тәгълиматына каршы килмәслек итеп оештырыла. Ә бит анда да шул ук теләк-догалар, әфсеннәр әйтелә.

Әфсеннәргә килсәк, телибезме-теләмибезме, ярыймы-ярамыймы – алар безнең тормышта, яшәештә бар. Без бүген аларны яшәештәге әхлакый нормаларга яраклаштырып куллана белергә һәм рухи мирас буларак, киләсе буыннарга сакларга тиеш.

Аңа кадәр әфсеннәрнең ике компоненттан торуын ассызыклап китәргә тиешбез: аларның текст аша бирелгән магик эчтәлеге һәм йола-ритуал өлеше (сулыш өрү, кул учы яисә канат белән сыйпау, тире белән тартылган барабан, таба кагу, тәкеренү, төтен төсләтү, ысылдау (елан булып), ышылдау-пышылдау (ияләр тавышы), ыжылдау (җил булып), су бөркү, үлән чәчү, төймә кою, кот кою, сөяк шылтырату, борчак, ярма сибү, таш йөгертү, чәч, җеп бөртеге «бүләк итү» һәм башкалар. Әфсен иясе шуларның икесен дә (эчтәлеген һәм хәрәкәт-йоласын) төгәл белергә тиеш. Аларның берсен генә төгәл үтәмәгән очракта да теләк, ният гамәлгә ашмый, әфсеннең көче кими яисә бөтенләй ялгыш юлга кереп китә, юкка чыга...

Имләүнең, өшкерүнең дә үз фәлсәфәсе бар. Әфсен текстлары, гадәттә, табигать һәм кеше, космос (күк) һәм кеше арасындагы янәшәлеккә нигезләнеп иҗат ителгәннәр; шушы янәшәлек магик тәэсир итү көче – тылсым тудыра, дип санаганнар...

Мондый янәшәлек берничә дәрәҗәдә карала ала:

1. Тән (гәүдә) – җир («җир симерә», «җир ябыга» дию шуннан килә).

2. Кан – су («елгалар – җирнең кан тамырлары»...)

3. Чәч – үсемлекләр.

4. Сөякләр, тешләр – таш.

5. Күзләр (караш) – Кош.

6. Колак, ишетү – дөнья, ил.

7. Җан (тын, сулыш) – җил.

8. Баш (түбә) – күк.

9. Гәүдәнең төрле өлешләре – кешеләр, рухларның төркемнәре.

Шул рәвешле, кеше, тәннең тегә яки бу өлеше авырган очракта, авыруга әлеге табигать күренешләре, космогоник (җанлы космос) һәм анимистик (җанлы табигать) элементлар аша тәэсир итәргә омтыла.

Ә хәзер берничә әфсен төреннән үрнәкләр карап китәрбез.

## Авыру, чир куу

Борынгылар чир-авырулар Су, Җир, Күк, Һава ихтыярында дип уйлаганнар. Шуңа да, «чир куганда», шундый әфсеннәр әйткәннәр:

Су анасы – сылу сакал,
Җир анасы – җирән сакал.
Күк анасы – көрән сакал,
Мине ашама, мине эчмә,
Саулыгымны саклап кал!..

* * *

– Ни булган?
– Чалпу булган.
Шуны имлим.
Бер, ике, өч,
Бер – белексез булсын,
Ике, өч – очсын китсен,
Дүрт, биш – бизсен китсен,
Алты, җиде – җилгә, кузга,
Сигез, тугыз – туң туфракка,
Ун – уңагай якка.
Имләп, кайтмасаң,
Миңа оят,
Имләп, кайтсаң,
Сиңа оят.
Тфү, тфү!
Минем телем түгел,
Гайшә-Фатыйма теле.
Тфү, тфү!
Име-томы шул булсын!

* * *

Миннән мидәт булсын,
Синнән сихәт булсын,
Кибәк урынына киптерәм,
Тузан урынына туздырам,
Сары май күк эретәм.
Име-томы шул булсын,
Каян килгән, шунда китсен!

* * *

Име-томы шул булсын,
Бардан артык имин кәтмә,
Каян килдең шунда кит.
Ай да кайта, көн дә кайта (көн – Кояш),
Мин дә кайтам, син дә кайт,
Илдән килсәң, илгә кит,
Җилдән килсәң, җилгә кит,
Кайта, кайта, кайт!..

* * *

Ак атка атланып куармын,
Кара атка атланып куармын,
Күк атка атланып куармын,
Тимер көрәк белән кырырмын,
Тырма белән тырнармын,
Тимер себерке белән себерермен,
Кырдым, тырнадым, себердем.
Тфү! Тфү! Тфү!

* * *

Идән астында тимер бүкән,
Аның өстендә карчык.
Энәсе коңгыр, җебе кызыл,
Име-томы шул булсын!

* * *

Күктә болыт ничек таралалдыр,
(Фәләннең) чәчәге шулай таралсын;
Су өстенә күбек ничек таралалдыр,
(Фәләннең ) чәчәге шулай таралсын;
Учак урынындагы көл җилдә ничек очадыр,

(Фәләннең) чәчәге шулай очып таралсын;
Болыт кебек таралсын,
Күбек кебек таралсын,
Көл кебек таралсын!
Име-томы шул булсын!
Каян килгән шунда китсен!
Тфү! Тфү!

## Күз тиюдән имләү

Ак Иделдә ак үрдәк,
Күк Иделдә күк үрдәк,
Аның башын кем исәпләп чыкса,
Шул чагында (фәләнгә) күз тисен.
Су буенда су яры,
Су ярында су ташы,
Шул ташны исәпләп чыкса,
Шул чагында (фәләнгә) күз тисен.

* * *

Кара болыт киләдер,
Кара болыт астыннан
Кара сыер киләдер,
Мөгезе күккә тигән,
Җилеме җиргә терәлгән.
Бер имчәгеннән кан килә,
Бер имчәгеннән май килә,
Шуны аша да эч.
(Фәләнгә) тимә, кагылма!

## Егылганнан әфсен

Арыдым-алҗыдым да
Җирдән рөхсәт сорадым;
Мәрхәмәтле туфраган
Сөеп тотып карадым.
Шайтан күзе тимәсен,
Рәнҗетмәм Җир Инәсен,
Кач, авыру, кач,
Мenә сиңа таш, –
дигән әфсен сүзләре әйтеп, егылган җиргә таш куеп калдыралар.

## Зәхмәт кагылудан әфсен

Җир атасы – җирән сакал,
Су атасы – суган сакал,
Җир анасы – сынлы бикә,
Җир кендеге – бер,
Су кендеге – бер.
Җирдән килсәң – җиргә кит,
Судан килсәң – суга кит,
Минем кулым түгел,
Имчеләр, корткалар, карыйлар кулы,
Гайшә-Фатыйма кулы,
Тфү! Тфү!

* * *

Кояш баегач, ишегалдындагы бер бик чиста урынны сайлап, кадак (чөй) кагалар да күлмәк изүе аша шуңа тоз сибеп, әфсен әйтәләр:
Җир атасы, Җир анасы,
Тоткан булсаң, җибәр,
Син шундый фәһемле,
Син шундый да чибәр!
Мин сиңа аш-су бирермен,
Син миңа йомшаклык бир!

## Куркуны куу әфсене (кот чакыру)

Әйтик, бала бик курыкса, чәршәмбе көнне таң суына дога укып өрәләр, котын чакыралар *(«коты очкан», «коты чыккан», ягъни курыккан)*:
Кер, котым, кер, котым,
Ишектән дә кер, котым,
Тишектән дә кер, котым,
Каян чыксаң, шунда кер,
Каз кебек какылдап кил,
Энҗе кебек тезелеп кил,
Ефәк кебек сузылып кил,
Каян чыктың, шунда кер,
Кер, котым, кер, котым!..

## Табигать әфсеннәре

Алтын капка ачылсын,
Көмеш капка ябылсын!
Мәрди бабай кычкырсын!
Үлгән кеше терелсен!
Йа Раббым,
Үлгән җаннар терелсен!
*(Таң әфсене. Таң атуга, әтәч кычкыруга, кешеләр уянып чыгуга һәм көн яктыруга ишарә.)*

# Ат тоягы кыздыру

(ФОЛЬКЛОР КҮРЕНЕШ)

**Ләйлә Мөхәммәтгалиева,**
*Арча районы, «Хәзинә» фольклор коллективы җитәкчесе*

Борынгыдан килгән гадәт буенча, ир бала кечкенәдән ат иярли белергә, үсмер егет Сабан туенда ат чабышында катнашу өчен, чабышкыларын алдан әзерләргә тиеш булган. Бу йола-гадәтне «Ат тоягы кыздыру» дип атаганнар. Арча якларында әлеге йола Иске Кырлай авылында үткәрелгән. Сабан туена иң җитез, иң чыдам чабышкыларны әзерләү өчен егетләр алдан сөйләшеп ачык мәйданчыкка, болынга җыелганнар. Атларның әзерлеген карарга авыл агайлары, авыл яшьләре килгән. Кайберләре кайсы атның беренче киләчәген дә фаразлаганнар.

Сентябрь аенда Арча районының Яңа Кырлай авылында Ат көне бәйрәм итела. Ат чабышларыннан тыш, бирeдә, «Иң үрнәк арба», «Иң тиз йөк ташучы» бәйгеләре, «Аударыш» уены уздырыла. Бәйрәмгә килгән халык «Ат тоягы кыздыру» дип аталган фольклор күренеш белән дә таныша ала.



**КАТНАШАЛАР:**
Инсаф Мөхәммәтгалиев (Габдулла),
Дилүс Сәләхов (Хәлил),
Алмаз Хаҗиев (Гомәр),
Фирдүс Шәрәфетдинов (Җәмил),
Илназ Абзалов (Әхмәт),
Динар Бариев (Вәли) – *авыл егетләре;*
Фәнис Тимашев (Сабир) – *авыл агае;*
Адилә Нотфуллина, Зөлфия Яббарова,
Фәрдия Дерин, Гүзәл Нигъмәтҗанова –
*авыл кызлары.*

**Сабир:**
Әйдәгез, әйдә, оланнар! Бүген эш кызу булачак. Атларыгызның чабышка әзерлеген тикшереп, барысын да тәртипләп куймый булмас. Карап килдем, куәтле атлар бар.
**Габдулла:**
Әй! Сабир бабай, егетләр белән бу көнне ничек көткәнебезне белсәң икән?! Үзең күрәсең, син бер чакыруга йөгереп килеп җиттек. Монда кайнашу, «ат тоягы кыздыру» безнең өчен зур бәйрәм инде ул. Иртән Җирәнкәй янына кереп, кишер белән сыйлап чыктым әле үзен. Ялларын туздырып, кешнәп үзенең бәйгегә әзерлеген белдерде. Атлар күңеле дә ярыш җиткәнен тоемлый!
**Хәлил:**
Дөрес әйтәсең, Габдулла. Чабышка әзерләнгәндә ат йөрәге белән синеке бергә кушылып, дөп-дөп тибә башлый. Ат чабышы төшләремә керә, егетләр. Мәйдан тулы халык миңа һәм «Кашка»га көч биреп тора. Тузаннар күтәрелә, җил чәчләрне тарый. Атым еш-еш сулый, ә син тын да алмыйсың. Чабабыз, юк очабыз гына. Очабыз, очабыз, очабыз...
**Әхмәт:**
Күпме очарга була инде, җиргә төш Хәлил. Ахыры ничек бетә соң бу төшнең?
**Хәлил:**
Ахырын белмим егетләр, әти печәнгә уятты.
**Барысы бергә:**
Эх, иң кызык җирендә...
**Сабир:**
Сезнең атлар турында шулай ялкынлап сөйләвегезгә күңел сөенә, оланнар. Кечкенәдән атлар арасында кайнашкан, тезген тотып үскән егетләр шул сез.
Атсыз татар – канатсыз. Атка атланып, тезгенне нык тотып, татар дөньяны тетрәткән бит. Я, ярый, эшкә керешик. Кирәк-яракларны әзерлик тә, атларны ярыштырып карарбыз. Бүген күрше авыл егетләре дә ат тоягы кыздырырга җыелган, тиздән килеп җитәрләр, алар алдында сынатасы түгел.

*(Эшли башлыйлар. Кем пычак кайрый, кем келәшчә, кем дага тота.)*

**Барысы бергә:**
Булдырырбыз, сынатмабыз, Сабир бабай. Атларыбыз да, үзебез дә әзер.
**Вәли:**
Күрше авыл егетләренең борыннарына чиертербез. Без булдыра алмас эш булмас.









**Барысы бергә:**
Шулай, шулай.
**Сабир:**
Яле, яле. Атларның дагаларын барлап куегыз. Киләшчәне дә дөрес тотыгыз. Игътибарлырак булыгыз! Кайрап куегыз.

*(Кызлар печән арасыннан башларын тыгалар, кешниләр.)*

**Адилә:**
Ми-ха-хай!
**Зөлфия:**
Ми-ха-хай!

*(Кычкырып көләләр.)*

**Әхмәт:**
Әллә чаптарлары белән күрше авыл егетләре төшеп җиткәннәр инде.
**Хәлил:**
Алай дисәң тавышлары бик ягымлы. Шул арада кызлар ат тоягы ялтыратуыбызны белеп тә алганнар. Кызлар! Кызлар, дим... Чыгыгыз әле.
**Адилә:**
Каян таныдыгыз?
**Зөлфия:**
Әй, аларга бит ат җене кагылган. Тавышны әйткән дә юк, күзләрен бәйләп куйсак та үз атларын таныячаклар.
**Габдулла:**
Кызлар, исәнмесез!
Кемнәрне сез көтәсез?
Атыбыз алтын дагалы,
Хәзер урлап китәбез.

**Кызлар:**
Урлатып торабыз ди сезгә.
**Гүзәл:**
Өер-өер айгырдан,
Җайдак булып килгәнсең.
Чаптыр атың чаптырып,
Кем янына килгәнсең?
**Вәли:**
Синең янга, әлбәттә.
**Әхмәт:**
Арчалардан ияр алдым,
Юлым сиңа ярдым мин.
Тимер булам, син күмер,
Җылытырга килдем мин.
**Фәрдия:**
Атларыгыз, әй атларыгыз,
Канатлы атларыгыз.
Безнең дә булыр микән,
Килен булыр чагыбыз?
**Габдулла:**
Үзем алам. Я, кызлар, чабыштан соң безгә бүләк итәргә кульяулык, сөлгеләрегез әзерме?
**Адилә:**
Бүләгемне соңгы килүче Нәзер атка әзерләдем. Сезгә, егетләр, уңышлар телибез!
**Сабир:**
Кызлар, без егетләр һәм аларның чабышкы атлары өчен җан атып торыйк. Хәерле сәгатьтә булсын!

**Фоторәсемнәр авторның шәхси архивыннан**

# Галимнәребез сукмагыннан
# ТӨРКЕСТАНГА СӘЯХӘТ

**Эльмира Сәлахова,**
*тарих фәннәре кандидаты, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институты өлкән фәнни хезмәткәре*

Күңел түрендә утырган күптәнге хыялым, бер заман шулкадәр ургылып чыгып, Үзбәкстан ягына сәяхәткә алып китте. Безнең Курсави, Мәрҗани, Барудилар аяк баскан, әле дә аларның җылысын, рухын саклаган мәдрәсәләрне, мәчетләрне үз күзләрең белән күрү, аларның ташларын сыйпау – тарихчы өчен бәхет иде.

Татар тормышы борын-борыннан Төркестан белән бәйле. Бабаларыбызның ислам белән танышулары да нәкъ бу төбәк аша башлана. Сәүдә белән шөгыльләнгән бабайлар мөселман гадәтләрен, аның кагыйдәләрен туган җирләренә – Идел буена алып кайталар, Ибн Фадлан җитәкчелегендәге илчелек килгәндә инде Болгар дәүләтенең зур өлеше мөселман булып, 922 елда Ислам дәүләтнең рәсми дине статусын ала.



Үзбәкстан ханымнары (Сәмәрканд)

Россиянең шәрык белән сәүдәсендә татарлар һәрвакытта арадашчы була. XVII гасыр ахырында Ташкент шәһәренә сәүдәгәр татарлар җәмгыятенең (Индия тарафыннан Төркестанга товар йөртүче Троицк татарлары) җитәкчесе Хайрабад ишан килә. Төбәк тарихчысы Борис Голендер фикеренчә, Ташкентның Иске шәһәрендәге XVIII гасырга караган архитектура истәлеге – Хайрабад ишан төрбәсе. Кызганыч, бу төрбә турында мәгълүмат аз, булганы да легенда дәрәҗәсендә генә сакланган. Хайрабад ишан – «шәрык Шекспиры» дип зурлана торган XIII гасыр шагыйре Җәләлетдин Руминың мәснәвиен[1] фарсы теленнән төрки телгә тәрҗемә иткән татар кешесе.

## Сәмәрканд һәм Бохара – татарның мәгариф мәркәзе

Татарлар белемле халык. Алар бар мөмкинлеген җыеп белем алырга омтылган. Ашарына, кияренә булмаган чакта да укуын калдырмаган. Һәр авылда мәктәп, мәдрәсәләр

[1] Фарсы поэзиясенең жанр формасы



«Әл-Мираб» мәдрәсәсенең ишегалды (Бохара)



Ш. Мәрҗани белем алган «Ширдор» мәдрәсәсе (Сәмәрканд)

эшләп торган. Сыйфатлы белем алу максаты белән, ара ераклыгына да карамыйча, алар ерак-ерак авылларга да, чит мәмләкәтләргә дә чыгып киткәннәр.

Урта Азия белән сәүдә эшләре, экономик мөнәсәбәтләр җайга салынуга татарларның бу төбәккә игътибары тагын да арткан. Алар бик теләп Төркестан мәдрәсәләренә укырга килгәннәр, мондагы уку йортларын тәмамлау мәртәбә саналган. Шуңа да Сәмәркандка, Бохарага барып укырга тырышканнар, мәхәллә дә, бирелә белем алган имам булсын дип, шәкертләрне укырга үз акчасына җибәрә торган булган. Безнең төбәктән беренчеләрдән булып беренче мөфти Мөхәммәдҗан Хөсәеневнең бабасы – Мансур Борындыкый Бохарага укырга киткән. Бохара мәдрәсәләре татар мәгърифәтчелегенә, мәгарифе үсешенә башлангыч биргән, җәдиди мәдрәсәләр ачучылар да Бохарада белем алганнар. Татар галимнәре Габденнасыйр Курсавый (1776-1812), Мөхәммәдҗан Хөсәенев (1756-1824), Шиһабетдин Мәрҗани (1818-1889), Габдрахман Утыз Имәни (1752-1836), Галимҗан Баруди (1857-1921) да Бохара мәдрәсәләрендә укып, татар тормышын яңача күргән, аның үсешен, дөньяда үз урынын табуын теләгән, шуңа бар гомерләрен багышлаган шәхесләр.

Бохараның һәр сукмагы әле дә аларның эзләрен саклый, «Әл-Мираб» мәдрәсәсе янына килгәч, аннан Ш. Мәрҗани үзе килеп чыгар кебек тоела. Мәдрәсә каршындагы Калон мәчетенә намазга йөргәндер, бер төркем шәкертләр күрше бинага авыз ачарга кереп киттеләр – алар арасында безнең хәзрәтебез дә бардыр сыман.

«Әл-Мираб» Ислам дөньясында данлыклы, күренекле уку йорты, бу уку йортын тәмамлап кайтучыларга халык «изге» дип караган, аларны «фәрештә»ләргә тиңләгәннәр, зурлаганнар, аларның сүзе һәрвакыт мәртәбәле булган.

«Әл-Мираб» 1535/36 елларда данлыклы шәех Мир-и Араб тарафыннан төзелгән мәдрәсә, әлеге исем аңа хуҗасының вафатыннан соң бирелгән. Бу уку йорты Пои Калон архитектур ансамбленең бер өлеше булып тора. Монда хәзер дә шәкертләр укый, әмма 1920 елда Бохараны Кызыл Армия яулап алганнан соң атаклы мәдрәсә эшләүдән туктаган, ә мөгаллимнәре репрессияләнгән. Әлеге уку йорты



Калон Хуҗа манарасы һәм мәчете
(Бохара)

эшчәнлеген 1946 елда гына яңартып җибәргән, берара Советлар Союзы территориясендә эшләүче бердән-бер дини уку йорты булып торган. Дини белем алу хупланмаган чорда да безнең төбәктән бу уку йортына белем алырга баручылар булган.

Биредә укыган Мөхәммәдҗан Хөсәенев – Россиянең беренче мөфтие. 1875-1882 елларда «Әл-Мираб»та белем алган Галимҗан Баруди (Галеев) 1883 елда, Казанга кайту белән, татар җәмгыятендә генә түгел, Ислам дөньясында дан тоткан мәшһүр «Мөхәммәдия» мәдрәсәсен ача.

Хәзерге чор дини эшлеклеләребездән Тәлгать Таҗетдин белән Равил Гайнетдин дә «Әл-Мираб» мәктәбе үтәләр.

Сәмәркand шәһәре дә дини белем үзәкләреннән берсе. Әтисенең мәдрәсәсендә белем алганнан соң Шиһабетдин Мәрҗани, укуын дәвам иттерү максаты белән 1838 елда, Төркестанның мәгариф үзәге – Бохарага юнәлә, аннан Сәмәркандның «Ширдор» мәдрәсәсенә күчә, укуын Бохараның «Әл-Мираб»ында тәгәлли. Аның биографиясендә нәкъ менә шушы уку йортлары хәлиткеч роль уйный.

Шиһабетдин Мәрҗани Бохарага килеп төшкәч, хакы арзанрак булган «Ишан хәлифә Ниязколый» мәдрәсәсенә урнаша, Бохараның иң карт, олугъ мөдәррисләреннән, атасының укытучысы – Мирзасалих Хөҗәндидән дәресләр ала. Аның вафатыннан соң башка атаклы мөдәррисләрдән белем ала, үзе дә укыта, китаплар күчереп, акча да эшли. Беркүпмедер вакыт Бохараның «Күкелташ» мәдрәсәсендә яши, әмма галим булып җитешкән тынгысыз Ш. Мәрҗанине иске укыту системасындагы тәртипләр канәгатьләндерми башлый, Бохарада 5 ел торганнан соң, Төркестан тарафының, Бохарадан кала, иң бөек гыйлем мәркәзе булган Сәмәркand шәһәренә сәфәр кылып, «Ширдор» мәдрәсәсенә урнаша. Монда ул Әбү Сәгыйдь хәзрәтләрендә белем ала, бу хәзрәт һәм аның бай китапханәсе Мәрҗанидә дини уку-укыту системасына реформа ясау теләге уята. Ш. Мәрҗанинең энесе Садретдин истәлекләреннән: «Мәрҗанинең Сәмәркандка барган елында Гарифҗан бай исемле бер хәерхаһ кешенең чыгымы илә, Сәмәркандта бер мәдрәсә салына торган булган. Бу мәдрәсәнең байтак эшләре казый Әбү Сәгыйдь ихтыярында булганга, Мәрҗанигә: «Быел Сәмәркандта кал, мәдрәсә төзелеп беткәч, бүлмәләренә шәкертләр урнаштыру минем ихтыярым илә булачак. Ул мәдрәсәдән сиңа да бүлмә бирермен. Шунда урнашырсың. Соңрак, гадәт буенча, бүлмәңне сатып китеп, акчасына Бохарадан үзеңә яхшы бер бүлмә алырсың», – дип сөйләгән. Мәрҗани моны кабул итеп, мәдрәсә төзелеп беткәч, аның бер бүлмәсенә урнашып тора башлаган. Ләкин беркадәр яшәгәч, Мәрҗани белән мәдрәсәнең бер мөдәррисе арасында низаг чыгып, бүлмәсен сатып, Бохарага китәргә мәҗбүр булган. Ошбу вакыйгадан соң Мәрҗани: «Шул бәдбәхет мөдәррис илә низагыбыз булмаса, мин Сәмәркандта калачак, Бохарага кайтмаячак идем. Минем өчен Сәмәркand файдалы иде», – дип сөйли иде.

Бохарага бу кайтуында «Әл-Мираб»ка урнаша, монда ул атаклы биобиблиографик хезмәте – «Вафияте әл-әслаф»ны яза башлый.

## Сәмәркand – тарих белән яңа тормышның үрелеп баруын чагылдыра торган шәһәр

Сәмәркand – бик үзенчәлекле шәһәр, ул заманча да, шул ук вакытта бик борынгы да. Берничә мәдрәсәне үз эченә алган Регистан комплексы күз явын алырлык, заманында шактый җимерелү хәленә җиткән биналарны бик оста итеп реставрацияләүләре хөрмәткә лаек. Шәһәрдә туристлар игътибарын яуларлык тарихи биналар бик күп. Безнең татар тарихында билгеле шәхес булган Аксак Тимер белән бәйле архитектур истәлекләргә аерым тукталасы килә. Аның хатыны – Биби Ханым хөрмәтенә төзелгән мәчет, Биби ханым төрбәсе искитмәле матур биналар.

Тарихта без Аксак Тимер буларак белгән әмир Тимер (1336-1405), көнбатыш тарихи историографиядә «Тамерлан» дип аталучы бөек шәхес, Үзбәкстанның Шаһрисаб шәһәрендә туа. Ул – көчле сугышчы, яулап алучы, дәүләте ярты Евроазияне биләгән. Көчле, куәтле Алтын Урдага Туктамыш хан (1388-1395) идарә иткәндә –


Биби Ханым мәчете (Сәмәрканд)


Әмир Тимер кабере (Сәмәрканд)


Регистан мәйданы (Сәмәрканд)

1391, 1395 елларда һөҗүм итә. Алтын Урданың көчсезләнүе, аннан инде җимерелүе, аерым ханлыкларга таркалуында барлык тарихчылар да диярлек нәкъ менә әмир Тимер һөҗүменең хәлиткеч булуын билгелиләр. Бер һөҗүмдә аягы яраланып, аксап йөргәнгә татар тарихына ул Аксак Тимер буларак кереп кала. Әмир Тимернең яулап алу планнары бик зурдан була, әмма ул 1405 елда Кытайга яуга барган вакытта авырып үлә.

1403 елда үзенең дәвамчысы булырга тиешле оныгы – Мөхәммәд солтан (1374-1403) үлгән була, аның өчен ул мавзолей төзетә, бу Сәмәрканд шәһәрендә Гур-и Әмир мавзолее дип атала. Бу төрбәдә әмир Тимернең остазы – Мир Сәед Барак (1404 елда үлә) һәм Тимер нәселе кешеләре җирләнгәнлеге, мавзолейда барлыгы 9 каберлек булуы билгеле.

Әмир Тимер кабере дә шунда. 1941 елның июнь аенда тикшерү өчен, башка версия буенча: янында «Интурист» кунакханәсен төзегәндә ялгышлык белән каберлекләрне су баса башлагач, каберлекләр ачыла. Халык арасында, 1941 елның июнь аенда Бөек Ватан сугышы башлангач, әмир Тимер каберлеген ачып «сугыш рухын» уяттылар дигән сүзләр тарала. Хәтта бу хакта «Проклятие Тимура» дигән фильм да төшерәләр. Биредә тәкъдим ителгән фотода Тимер каберлеге кара төстәгесе. Төрбә бик матур, каралган, туристлар бик күп килә.

Турист буларак кая гына килеп төшсәң дә, иң беренче аның халкына, аларның сина булган мөнәсәбәтенә игътибар итәсең. Әлбәттә, җирле халык та килгән кунакка ярарга тырыша, аның күңеле булсын өчен барын да эшли. Әмма мин бу юлы тур белән түгел, үзем генә килдем, гап-гади шартларга урнашып, мондагы халыкның яшәү рәвешен тою иде максатым. Иң шаккатырганы һәм сөендергәне кешеләрнең ихласлыгы, ачык йөзлелеге һәм ярдәмчеллеге булды. Сораган соравыңа итагатьле итеп җавап бирәләр, юл күрсәтәләр, интернетыгыз бармы, такси чакырып бирергә кирәкме дип ярдәмнәрен тәкъдим итәләр. Туристлардан мөмкин кадәр файдаланып калу дигән нәрсә дә юк монда, гидлар да үз хезмәтләрен тәкъдим иткәндә «хөрмәтлем» дип мөрәҗәгать итәләр, әгәр дә «рәхмәт, мин үзем генә карыйм», дисәң, кат-кат тәкъдим итеп аптыратмыйлар, тыныч кына читкә китеп басалар. Мин моны аларның чаялыгы, осталыклары булмау дип түгел, ә «тәрбияле туризм» дип атыйм. Бу бары хөрмәт кенә тудыра. Әмма шәһәрнең тарихын шул тирәдә сатучы да, син хезмәтен кулланмаган гид та сорамасаң да сөйли, аңлата. Мәгълүматны акчага гына сату дигән нәрсә аларга хас түгел икән. Базар, кибеттә сатучылар аерым игътибарга лаек. Базарга кереп аннан чыкканчы синең тамагың да туя, чәй дә эчерәләр. Һәр сатучы үз азыгын, татлысын кабып карарга тәкъдим итә, әле ул аны күпләп бирә, товарын алмыйча китсәң дә, кырын караш ташламый.

Тагын бер игътибарны җәлеп итә торган нәрсә ул – халкының киемендә милли элементларның күп булуы, миллилекне заманча итеп бирә белүе. Ирләр – түбәтәйдән, хатын-кызларның олырак буыны, үзбәкләргә хас булганча, чуар һәм ялтыравыклы күз явын алырлык киемнәрдән йөриләр; яшь кызлар арасында



**Базар (Бохара)**

милли киемне заманчалаштырып бик стильле киенү дә соклану уята; мәктәп формасы да түбәтәйдән, үзбәк бизәкләре төшерелгән тукымадан тегелгән киемнәрдән тора. Болар барысы да җирле халыкка карата соклану һәм ихтирам хисләре уята.

Үзбәк терминнары да бик кызыклы, алар көндәлек тормышта киң кулланыла, әлбәттә күбесе безнең уртак төрки тел сүзләре. Шундыйларга берничә генә мисал: «бассейн» сүзен татарча ничек әйтергә була? Татарчасы юк диярсез. Үзбәкчә ул «havuz», төрекчә дә шулай, чөнки ул төрки сүз. Ә татарда әлеге сүз телдән төшеп калган, ә нигә аны кулланышка кертмәскә? Бохарада XVI-XVII гасырларга караган сулык каршындагы архитектур ансамбль «Ляби хаус» дип атала. Мәсәлән, «паркинг» сүзен татарча ничек әйтеп булыр иде? Үзбәкләр моңа да бик кызык термин тапканнар, алар аны «машина колдирманг» дип атаганнар. Чит тел сүзләрен кулланмаулары да хөрмәт уята.

## «Бас, кызым, Әпипә...»

XV гасыр һәйкәле Хуҗа Даниёр төрбәсе янында Изге чишмә бар, шунда тукталганда без – татарларны шаккатырган вакыйга булды: ике үзбәк әкәсе (абзые) кайдан килдегез, дип сорады. Казаннан без, татарлар дигәч:

– Бас кызым, Әпипә.

Без:

– Син басмасаң, мин басам.

Үзбәк әкәсе:

– Синең баскан эзләреңә, мин дә китереп басам... – димәсенме!

Бу абзыйның классташы татар кызы булган икән, күпме еллар үтсә дә, аның татарларга булган хөрмәте сакланган, «Әпипә»не дә хәтерли! Мөсафир татарларга булган хөрмәтен абзый ничек белдерергә белмәде, пылау белән сыйлыйм, кая телисез – шунда алып барам да диде. Рәхмәт әйтеп, кире каккач, юлчыга сәдака булсын, миңа дога кылыгыз дип, акча сузды, аннары үз юлы белән китеп барды.

Казан белән Төркестан арасында тарихи якынлык зур. Бу халыклар борынгы чорда



Хайрабад ишан төрбәсе (Ташкент)

уртак юл үткәннәр, аралашканнар. Урта Азия халыклары арасында мәгърифәтчелек таратучылар – татарлар. Совет чорында да татар кешеләре мәгариф, фән, сәнгать өлкәсендә биредә хезмәт куйганнар, татар артистларының спектакль, концертлар белән килүләрен көтеп алганнар. Монда мин хәзергә кадәр татарга булган җылы мөнәсәбәт кенә очраттым, татарлар күп иде, киттеләр шул, дип искә алып та сөйләделәр. Татар теле үзбәк белән аралашу өчен бик кулай тел. Шунысын да әйтергә кирәк, яшь буын рус телен начар белә, бөтенләй белмәгәннәрне дә очраттык. Татар теле аша алар белән рәхәтләнеп аралашырга була, бу төбәктә рус теле олы совет буыны белән китеп бара сыман тоелды. Дөрес, Россиядә яшәп-эшләп кайтканнар сөйләшә, әмма алар илдәге халыкның бик аз өлеше генә. Тарих кабатлана, татар теле кабаттан төрки дәүләтләр белән аралашу теле югарылыгына күтәрелеп бара. Татарга тылмач кирәкмәгәненә инандыра торган сәяхәт булды бу.

Казан белән Үзбәкстан арасы ерак түгел, бу ике ил арасындагы юлны еш очып торган самолетлар да якынайта, төрки-татар тарихына киңрәк карау мөмкинлеге бирелә. Турист буларак, бу төбәкнең борынгы һәм бай тарихын, һичшиксез күрергә кирәк. Әлеге язмага Үзбәкстан турында мәгълүматлар һәм эмоцияләр бик аз керде, үз күзләрең белән күрүгә, күңелең аша уздыруга ни җитә?!

**Фоторәсемнәр ачык интернет ресурсыннан һәм авторның шәхси архивыннан**

# Без чигәбез асыл җепләр белән

Бөтендөнья татар конгрессы каршындагы «Ак калфак» татар хатын-кызлары республика иҗтимагый оешмасының Чистай бүлекчәсе шактый эшләр башкара. Кул эшләреннән тегү-чигү – ак калфаклыларның иң яраткан шөгыльләре булып тора.

Чиккән сөлгеләр, кульяулыклар, намазлыклар, калфак-изүләр – безнең тарихыбызның күркәм истәлекләре. Халкыбызның җәүһәрләре күзләребез аша безнең дә көннәргә күчеп бара. Арабыздагы өч ханым – Кадрия Әхмәтвәлиева, Фәүзия Җиһаншина, Гүзәл Вәлиева – кыска гына вакыт эчендә үзләрен оста чигүчеләр итеп таныттылар. Кул эшләреннән төзелгән күргәзмәләрнең зур өлешен әлеге ханымнарның кулы белән эшләнгән күп төрле чигешләр алып тора.

Бөтендөнья татар конгрессы тарафыннан оештырылган «Татарның мамык мендәрләре» республика бәйгесендә алар 3 буынга – әби-бабайга, әти-әнигә һәм 3 балага мендәрләр әзерләделәр, мендәр тышларына матур милли бизәкләр чиктеләр. Һәр буын мендәрләрен чигүчеләребез пар күгәрченнәр белән дә чигеп бизәделәр. Фәүзия ханым чиккән әти-әни мендәрләре бәйгедә 3нче дәрәҗә Дипломга лаек булды.

Әлеге мендәрләрнең күз явын алырлык матур чигешләре күңелемдә шигъри юллар тудырды:

Җиде мендәр өелеп тора астан өскә:
Әби-бабай, әти-әни, балалары...
Ишле гаилә мендәрләре – олы тарих,
Чигешләре – үткәннәре, хыяллары...

Аллы-гөлле чәчкәләре янып тора,
Төсле-төсле мулинәләр белән чиккән.
Чигүченең иң-иң нечкә хисләре дә
Башкаларның йөрәгенә барып җиткән...

Күгәрченнәрдәй гөрләшеп, бәхет белән,
Тигезлектә узсын иде тормышлары.
Әби-бабай, әти-әни, балаларның
Чәчәкләрдәй балкып торсын язмышлары.

Әби-бабай, әти-әни һәм балалар...
Бу бергәлек мәңге калыр тарихларда...
Яшәү яме, олы хикмәт чигешләрдә,
Нинди кодрәт, зур осталык бу кулларда.



Фәүзия Җиһаншина



Гасырлардан күчеп килгән бу чәчәкләр,
Һәрбер «атлам» – гүя йөрәк тибешләре.
Газиз халкым күңеленнән алынгандыр,
Ак калфаклы ханымнарның чигешләре.

Ак калфаклы ханымнар узган ел Мөслимдә (Мөслим районы) оештырылган «Тылсымлы энә» бәйгесендә дә бик теләп катнаштылар. Бу юлы алар зур гына эскәтер чигәргә алындылар. Гүзәл ханым матур милли бизәкләр төшерде, Кадрия ханым белән Фәүзия ханым аллы-гөлле мулинәләр белән аларны чикте. Бу бәйге Мөслимдәге кошчылык юнәлешендәге «Агро Лидер» кооперативы җитәкчесе Ирек Хәмәдишин инициативасы белән уздырылганга, бизәкләрнең уртасында татар халкының брендына әйләнгән каз рәсеме булу да шарт иде. 3х4 метр зурлыгындагы ашъяулыкны ханымнар шулкадәр зур тырышлык һәм осталык белән чиктеләр. Нәтиҗәдә, ханымнарның һәрберсе 1нче дәрәҗә дипломга һәм кыйммәтле бүләкләргә ия булдылар.

Оешмабызда татар халкының кул эшләренә зур урын бирелә. «Халкыбызның милли бизәкләре» исемле бәйге – моңа ачык бер дәлил булып тора. Бәйгедә районыбыз ханымнары, төрле техника кулланып чиккән кульяулыкларын һәм сөлгеләрен тәкъдим иттеләр. Тамбур чигүе кулланып сөлге чиккән Чистай районының Исләй авылында яшәүче Тәскирә Агрусева «Иң оста чигүче» дип билгеләнде.

Соңгы вакытта оешмабыз ханымнары тырнак алмалау техникасын үзләштерә. Күптән түгел ак калфаклылар белән очрашуга Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре, Татарстан Республикасының Рәссамнар берлеге вәкиле Әлфия ханым Нурхәмәтова килгән иде. Ул да биредәге ханымнарга тырнак алмалау техникасы буенча дәресләр уздырды. Беренчеләрдән булып, бу техниканы Гүзәл ханым Вәлиева үзләштерде. Хәзер инде кул эшләреннән торган күргәзмәбез шул техника нигезендә эшләнелгән калфаклар, изүләр, брошьлар белән баетыла.

Әлбәттә, ак калфаклыларның кул эшләреннән торган күргәзмәләре даими яңартыла, баетыла һәм шуңа да һәрвакыт кызыклы була.

**Рушания ЗАКИРОВА,**
**Бөтендөнья татар конгрессы каршындагы «Ак калфак» татар хатын-кызлары республика иҗтимагый оешмасының Чистай бүлекчәсе җитәкчесе**

**Автор фоторәсемнәре**



**Гүзәл Вәлиева**




**Сулдан уңга – Гүзәл Вәлиева, Фәүзия Җиһаншина, Кадрия Әхмәтвәлиева**




Татар халык әкиятләре = Татарские народные сказки = Tatar folk tales. – Казан : Татар. кит. нәшр., 2024. – 215 б.

# Көнгә күренмәс сылу-көмеш

Бездән бик ерак бер шәһәрдә бер бик ярлы карчык яшәгән. Бу карчыкның бер генә баласы булган, ди. Болар шәһәрнең ярлылар тора торган бер читендә торалар икән. Карчыкның улы кечкенәдән үк җәядән ук атарга бик тә ярата торган булган, ди. Унбиш-уналты яшьләренә җиткәч, бу егет кырларга чыгып, урманнарга барып, кош-кортлар атып алып кайта икән дә, ди, болар шуның белән алай-болай итеп көннәрен авыштырып баралар икән, ди.

Бу шәһәрнең уртасында, патша сарайлары тирәсендә, шактый зур бер күл булган икән. Көннәрдән бер көнне карчыкның улы кулына җәясен, угын алган да, ди, иртүк торып, «тукта әле, шәһәр уртасындагы, патша сарае тирәсендәге күл янына таба барып карыйм әле, шунда берәр кош-корт очрамасмы, анда барган өчен мине асмаслар-кисмәсләр, ассалар-киссәләр дә кайгырырлык урын юк», дип, өеннән чыгып киткән, ди. Бу шәһәр бик зур шәһәр икән, ди. Егет шәһәр уртасындагы күл янына барып җиткәнче, кояш төш турыннан авыша да башлаган, ди.

Егет, күл янына барып җитеп, җәясен җайлап утырган чагында, ни күзе белән күрсен, күл буендагы камышлар арасыннан бер энҗеле үрдәк пыр итеп очып чыккан да, ди, егетнең баш түбәсе турыннан үтеп барганда, егет моны атып төшергән, ди. Егет үрдәкне алган да, туп-туры патша сараена барып, рөхсәт сорап, патша янына кергән, энҗеле үрдәкне патшага бүләк итеп биргән. Патша бу егеткә энҗеле үрдәк китергәне өчен бик күп акча биреп чыгарган, ди.

Шуннан соң патша сараендагы тегүчеләр бу энҗеле үрдәкнең каурыйларыннан, йоннарыннан патшага бик матур бер бүрек тегеп биргәннәр, ди. Менә берзаманны патшаның якын вәзирләре, теге карчыкның улыннан көнләшеп, киңәшләшкәннәр дә патшага әйткәннәр:

– Әй безнең зур, тирә-якта данлыклы патшабыз, хәзер инде синең энҗеле үрдәктән бүрегең булды, тагын энҗеле тәкәдән туның да булса, бигрәк тә яхшы булыр иде. Күрше патшалар арасында данлыгың тагын да артыр иде, – дип.

Вәзирләрнең бу сүзләре патшага бик ягымлы тоелган.

Патша вәзирләреннән:

– Энҗеле тәкәне каян табарга, каян алырга икән соң аны? – дип сорады, ди.

Вәзирләр патшага:

– Аңа бер дә аптырап торасы юк. Аны әнә теге энҗеле үрдәкне китергән егет табып алып кайтырга тиеш, – дип әйттеләр, ди.

Патша шул көнне үк теге карчыкның улын сараена чакыртып:

– Син миңа энҗеле үрдәк табып китерә алган идең, инде хәзер энҗеле тәкә дә табып китерергә тиешсең. Казнадан юлыңа җитәрлек акча ал да бүген үк чыгып кит. Әгәр шул энҗеле тәкәне табып кайтмасаң, мин синең башыңны кистерермен! – дип әйткән.

Егет, патшадан бу сүзләрне ишеткәч, нишләргә дә белмичә аптырап, анасы янына

кайтып киткән, ди. Анасы улының бик күңелсез генә кайтып керүен күреп:

– Әй улым, сиңа нәрсә булды, әллә авырыйсыңмы, төсең-битең агарган, иреннәрең күгәргән, әллә явыз патша синең кулыңнан килмәслек берәр эш куштымы, әйт әле? – дип сораган.

Егет патшаның нинди эш кушканын анасына әйтеп биргәч, анасы әйтә моңа:

– Улым, бер дә кайгырма, җир йөзе бик бай бит ул, анда энҗеле тәкә генә түгел, әллә нинди кыйбатлы әйберләр дә бардыр әле. Җаяң белән укларыңны кулыңа ал да юлга чык, Ходай кушмаган эш булмас, – ди.

Шуннан соң бу егет патша казнасыннан бирелгән акчага бер ат алып, юлына азык хәзерләп, җәя белән укларын алган да юлга чыгып киткән.

Ай барган, ел барган бу, бара торгач, караңгы бер урманга барып кергән. Урман эчендә утырган бер кечкенә генә өйгә барып җиткән. Өйгә килеп кергән. Өй эчендә ап-ак чәчле, тешләре төшеп беткән бөкре бер карчык утыра икән, ди. Килеп керү белән, егет бу карчыктан исәнлек-саулык сорашкан да, ди, үзенең башына төшкән эшне сөйләп биргән. Шуннан соң бу егеткә карчык:

– Улым, бүген син миндә кунак бул, син сораган нәрсәне мин белмим, аны минем тутам белсә белер, иртәгә шуның янына барырсың, ул моннан бик ерак түгел, – дигән.

Егет, иртәгесен йокыдан торып, ашап-эчкәч, карчыкка бик күп рәхмәтләр әйтеп, атына атланып, юлга чыгып киткән.

Теге карчык өйрәткән юл белән көн барган, төн барган бу. Бара торгач барып җиткән тузан-туфраклы кап-кара кыр уртасында япа-ялгыз калган кеп-кечкенә генә бер өйгә. Атыннан төшеп, рөхсәт сорап, егет өйгә барып керә.

Өй эчендә бөкрәеп беткән, ап-ак чәчле, бик ябык бер карчык утыра икән. Егет карчыктан исәнлек-саулык сорашкан. Шуннан соң бу карчык егеткә әйткән:

– Улым, синең башыңа бик зур эш төшкәндер, ахры, югыйсә мондый ерак җиргә килеп чыкмас идең. Монда адәм баласы бик сирәк килә. Дөресен әйт, башыңа нинди авыр эш төште? Кулымнан килсә, мин сиңа булышырмын, – дигән.

Карчыктан мондый җылы сүзләр ишеткәч, егет иркен сулап әйтә:

– Дөрес, әби, – ди, – минем башыма бик зур эш төште, – ди. – Мин фәлән патша тора торган фәлән шәһәрнең читендәге бер йортта бик ярлы гына көн күреп торучы бер карчыкның улымын, мин әтидән бер-ике айлык кына чакта калганмын. Әни мине шул шәһәрнең байларына кер уып, аш пешереп тапкан азыклары белән үстерде. Үсеп җиткәч, мин патшага бер энҗеле үрдәк атып биргән идем. Хәзер ул: «Син миңа каян булса да энҗеле тәкә табып китер. Әгәр фәләнчә вакытка кадәр табып китермәсәң, башыңны кистерәчәкмен», – диде. Менә мин шул энҗеле тәкәне эзләргә чыктым, табып алып кайтмасам, патша башымны кистерә минем, – ди.

– Әй улым, – дигән карчык, – бер дә кайгырма син. Бүген син минем кунагым. Ашап-эчкәч тә ятып йокла, ял ит. Иртәгә иртүк торып китәрсең, теләгәнеңне табарсың.

Шуннан соң бу егет әйбәтләп ашап-эчкән дә, ди, ятып йоклаган, ди. Иртә белән торып, ашап-эчкәч, егет юлга хәзерләнгән. Китәр алдыннан карчык әйткән моңа:

– Менә, улым, – дигән, – моннан ерак түгел бер җирдә минем бер тутам бар, аның җир-суы, урман-болыны киң, кош-кортлары, мал-туарлары бик күп. Сиңа кирәкле энҗеле тәкә шуның көтүләрендә булмый калмас. Бар, син энҗеле тәкәне шул тутамның көтүеннән табарсың, – дигән.

Егет, карчыкка бик күп рәхмәтләр әйтеп, юлга чыгып киткән. Көн бара, төн барган бу. Бара торгач, барып җиткән ямь-яшел болынлыкка. Шул болында йөргән көтүләрнең берсеннән, теге карчык өйрәткәнчә, бер энҗеле тәкәне тотып алган да ат өстенә салып алып кайтып киткән. Атна кайта, ай кайта бу. Бик күп заманнар үткәч, кайтып җитә үзе торган шәһәргә. Шәһәргә керү белән, туп-туры патша сараена барып, теге энҗеле тәкәне патша әйткән көнгә алып кайтып тапшыра. Патша бу егеткә төрле-төрле бүләкләр биреп, өенә кайтарып җибәрә. Егет анасы янына кайтып, аның белән бик яхшы гына итеп тора башлыйлар, ди.

Патша энҗеле тәкә тиресеннән тун тектерә. Бу тун шул тирәдә бердәнбер тун булып, патша моның белән бик мактана икән, ди. Тирә-ягындагы барлык патшаларны чакыра бу кунакка. Күрше патшалар аның энҗеле үрдәк каурыйларыннан тегелгән бүреген, энҗеле тәкә тиресеннән тегелгән тунын күреп таң калалар. Теге карчыкның улы аркасында, патша шул тирәдә дан ала инде. Патша мәҗлескә теге карчыкның улын да чакыра, чакырмый булдыра алмый. Мәҗлес бетеп, кунаклар таралу белән, патшаның вәзирләре үзара яшерен киңәш итәләр: «Бу егетне юк итмәсәк, тора-бара патша аны бездән артык күрер», – диләр. Шуннан соң, мин сезгә әйтим, патшаның вәзирләре бераздан соң патшага әйтәләр:

– Әй безнең бөек, данлыклы патшабыз, без бик яхшы беләбез, синең тирә-якта кодрәтең зур, җирең-суың киң, әйләнә-тирәдәге барлык патшалар сиңа түбәнчелек белән карыйлар, синнән куркалар. Синең даныңны тагын да арттырырга кирәк иде, – диләр.

Патша, вәзирләреннән мондый мактау сүзләре ишетүенә бик шатланып:

– Ярый, ярый, бик яхшы, тик менә минем данымны ничек итеп зурайтырга кирәк соң? – дип сораган, ди.

Вәзирләр барысы да беравыздан патшага:

– Әй безнең данлыклы патшабыз, менә синең энҗеле үрдәктән бүрегең, энҗеле тәкә тиресеннән тегелгән туның булды. Инде сиңа көнгә күренмәс Сылу-көмеш кирәк. Шул да булса, тирә-як патшалары арасында синең даның тагын ун өлеш, йөз өлеш артачак, – дигәннәр.

Шуннан соң патша, бик уйга калып, вәзирләрдән:

– Ул нәрсә соң? Аны каян, кем табар? – дип сораган, ди.

Вәзирләр:

– Әй бөек патшабыз, аның нәрсә икәнен табылгач кына белә алырсыз, аны теге карчыкның улы табып китерсә китерә алыр, башка кеше булдыра алмас, – диләр.

Патша, бу көнгә күренмәс Сылу-көмеш белән бик кызыксынып, вәзирләр чыгып китү белән, теге карчыкның улын чакыртып ала да әйтә:

– Син, батыр егет, миңа энҗеле тәкә, энҗеле үрдәк табып китердең, әгәр син батыр булсаң, миңа тиз арада көнгә күренмәс Сылу-көмешне дә табып китер. Әйткән вакытка табып китермәсәң, мин синең башыңны кистерермен. Юлыңа кирәкле акчаны хәзер үк казнадан ал да чыгып кит! – ди.

Егет, патшадан шул боерыкны ишеткәч, нишләргә дә белмичә, башын иеп кенә кайтып китте, ди. Өенә кайтып, юлга әзерләнә дә, анасы карчык белән саубуллашып, көнгә күренмәс Сылу-көмешне эзләргә чыгып китә. Атна китә, ай китә бу. Бара-бара, теге беренче карчыкка барып җитә. Аның янына кереп, үзенең кайгысын сөйли. Теге карчык әйтә:

– Кайгырма, улым, – ди, – син минем уртанчы тутам янына бар, кайгыңны сөйлә, ул сиңа ярдәм итәр, – ди.

Шуннан соң егет бу карчык өендә бер көн генә ял итә дә, карчык өйрәтүе буенча, аның уртанчы тутасына китә. Бара-бара, уртанчы тутасына барып җитә. Уртанчы тутасы бу егетне бик яхшылап каршы ала, ашата, эчертә. Егет моңа да үз кайгысын сөйләп бирә.

– Әй улым, – ди карчык, – бер дә кайгырма, энҗеле тәкәне тапкан җирдә син көнгә күренмәс Сылу-көмеш кызны да табарсың. Ул кыз әнә шул энҗеле тәкәләр хуҗасы карчык – безнең иң карт, иң бай тутабызның сараенда, җиде кат капка, җиде кат ишек, җиде кат дивар, җиде кат түшәм, җиде кат түбә, җиде кат идән, җиде кат тәрәзә эчендә, көнгә-айга күрсәтелмичә, Сылу-көмеш булып утыра. Капка каравылчыларына кием-салым бирерсең, үгез алдындагы сөякне эт алдына, эт алдындагы печәнне үгез алдына салырсың. Капкалар, ишекләр ачылыр, кап-караңгы җиде төн уртасында көнгә күренмәс Сылу-көмешне алырсың да юлга чыгарсың, – ди.

Бу сүзләрне ишеткәч, егет бик шатланып, карчыкка бик күп рәхмәтләр әйтеп, шул минутта ук юлга чыгып китә, ди. Көн китә, төн китә, бара-бара, җиде төн уртасында әлеге бай карчыкның сараена барып җитә. Капка каравылчыларына кием-салым биреп, үгез алдындагы сөякне эт алдына, эт алдындагы печәнне үгез алдына алып салуы була, капкалар, ишекләр ачыла да китә. Егет, сарай эченә кереп, көнгә күренмәс



Булат Гыйльванов рәсеме

Сылу-көмешне күрү белән, исеннән-акылыннан китә яза, ди. Алай да үзен нык тотып, шул минут эчендә көнгә күренмәс Сылу-көмешне күтәреп алып чыга да, атына атланып, кызны үзе белән алып китә.

Ярар, егет белән көнгә күренмәс Сылу-көмеш шулай бара торсыннар, без карчыкка килик. Карчык иртә белән торып чыкса, Сылу-көмеш торган йортның ишекләре ачык, кыздан җилләр искән. Каравылчылар әр-яңа киемнәрдән йөриләр, эт рәхәтләнеп сөяк кимерә, үгез мышный-мышный печән ашый, капкалар, ишекләр ачык, ди. Карчык, ачуыннан нишләргә дә белмичә, чәчләрен йолкый-йолкый каравылчыларга ташлана.

Каравылчылар:

– Сиңа ничә ел хезмәт итеп, син безгә яңа кием алып бирмәдең. Безне әр-яңадан киендерүчегә без капкаларны, ишекләрне ачтык. Бездә гаеп юк, гаеп синең үзеңдә, – диләр.

Шуннан соң карчык эт янына барып, аны кыздыра башлады, ди. Шул вакытны эт, телгә килеп:

– Син шулхәтле байлыгың белән миңа ит кенә ашатып торасы урында, сөяк тә кимертмәдең, алдыма печән куйдың. Мин үземә сөяк салган кешегә өрергә кыймадым. Гаеп миндә түгел, синең үзеңдә, – ди.

Шуннан соң карчык, үгез янына барып, аны да сүгә башлый. Үгезнең карчык сүзенә исе дә китми, ди, мышный-мышный печән ашавын гына белә, ди. Карчык, ачуыннан нишләргә дә белмичә, уртанчы сеңлесенә китә. Аңа әйтә:

– Минем сараемда көнгә күренмәс Сылу-көмеш барлыгын синнән башка беркем дә белми иде. Кемгә сөйләдең, кем белән качырдың аны, әйт дөресен? – дип, аны кыздыра башлаган иде, сеңлесе дә аңа:

– Кызма, кызма, тутам. Синең шулхәтле җирең-суың, мал-туарың була торып, гомерең буена син миңа бер шырпы да бирмәдең. Ә менә ул егет миңа бүләкләр биреп, рәхмәтләр әйтеп китте. Көнгә күренмәс Сылу-көмешле дә булды. Синең белән алыш-бирешем юк, минем тирәмдә йөрмә, – ди.

Сеңлесеннән шул сүзләрне ишеткәч, карчык нишләргә дә белмичә сараена кайтып китә, ди. Егет көнгә күренмәс Сылу-көмеш белән үзләренең шәһәренә кайтып җитеп, патша сараена барып керәләр. Патша, көнгә күренмәс Сылу-көмешне күрү белән, исеннән-акылыннан китә язып, кызга гашыйк була. Шуннан соң вәзирләрен чакырып, үзенең Сылу-көмешкә өйләнәчәген әйтә. Моны ишетү белән, Сылу-көмеш:

– Юк, син миңа тиң түгел. Мин бер ярлы кеше кызы идем. Кечкенә чагымда мине бер карчык урлап алып китеп, айга-көнгә күрсәтмичә, шушы яшемә хәтле җиде капка, җиде кат дивар эчендә асрады. Бәхетемә каршы, бу батыр егет килеп чыгып, мине явыз карчык кулыннан коткарды. Ул – мине, мин аны яратам, шуның өчен мин аңа булырга тиеш. Әгәр безгә каршы киләсез икән, менә бу батыр барыгызның да башын чабып өзәр, – ди.

Патша да, аның вәзирләре дә, егеттән куркуларыннан, тәхетне ташлап чыгып китәләр. Егет шул илгә патша булып калып, болар матур гына гомер иткәннәр, ди.

Шәвәлиевлар гаиләсе чыгышы




# «Туган нигезгә җыелу» йоласы

**Гөлфинур Зәйнакова,**
**Рәмзия Гарифуллина,**
*Арча районының 10нчы балалар бакчасы тәрбиячеләре*

*(Бәйрәмчә табын әзерләнгән. Әби бәлеш тотып өстәл янына килә. Бабай баянда татар халык көен уйнап керә.)*

**Бабай:**
Бүген минем туган көн,
Бәйрәм була торган көн.
Үткән әз-мәз тормышымны,
Бәйрәм итә торган көн.

**Әби:**
И бабасы, шушы яшькә җитәргә дә насыйп булды бит.

**Бабай:**
Гомер үтсә дә, күңел унсигездә әле, әбисе.

*(Бергәләп «Картаямыни соң йөрәк» җырын башкаралар. Сафьян Ибраһимов көе, Гата Нуруллин сүзләре.)*

Картаямыни соң йөрәк,
Маңгайлар сырланса да.
Үтте яшьлек – җүләрлек дип,
Җырларда җырланса да.

**Әби:**
Балалар да кайтып җитә торгандыр инде, юлда дигәннәр иде.
Бабай тәрәзәгә карап:
Әнә, кайтып та җиттеләр...

*(Уллары, киленнәре, оныклары бүләкләр, шарлар тотып килеп керәләр. Бергәләп исәнләшәләр, күрешәләр, кочаклашалар.)*

**Әби:**
Исән сау гына кайтып җиттегезме, балакайлар?

**Оныкъ:**
Бабаем, әбием, мин сезне шундый сагындым!
Туган көнең белән сине, бабай,
Чын күңелдән котлыйбыз!
Бәхет, шатлык, сөенеч,
Озын гомер телибез.

*(Бабасына шар тоттыра.)*

**Уллары:**

Әти, сиңа бүләккә матур итеп чигелгән түбәтәй алып кайттык. Кая киеп кара әле. Бик килешеп тора икән үзеңә!

**Бабай:**

Рәхмәт, балаларым!

**Киленнәре:**

Әнкәй, сиңа да бүләгебез бар. Шушы бизәкле ефәк яулыкны җилкәләреңә салып, чын татар әбие булып йөр.

**Әби:**

Рәхмәт яусын, Виктория, кызым. Әйдәгез, мул табыннарыбыз әзер. Түргә узыгыз!

**Уллары:**

Озакламый абыйлар да, сеңлебез дә кайтып җитәр...

**Киленнәре:**

4 оныгыгыз, 3 балагыз өстәлгәч, табыннар тагын да түгәрәкләнер.

**Онык:**

Бабай, мин сиңа бүләккә бер матур җыр әзерләдем.

**Бабай:**

Әйдә әле улым, җырлап җибәр, мин көен тартырмын.

*(Бабай баянда уйный, оныклары Руслан «Иң шәп бабай» җырын җырлый.)*

Сөенеп туймас балачак,
Иң бәхетле балачак.
Бабай белән үткән кичләр,
Мәңге истә калачак.
Яратабыз сине бабай,
Син бит безнең бер генә.
Нурлы йөзле, шат күңелле,
Иң шәп бабай син генә!

**Бабай:**

Рәхмәт, балакаем! Улым, син – безнең нәсел дәвамчыбыз. Безнең нәсел – гармунчылар нәселе. Бездән бүләк – беренче гармуныңны кабул итеп ал әле.

**Онык шатланып:**

Нинди яхшы бүләк бу, бабай. Рәхмәт! Зур үскәч мин дә гармунчы булырмын.

*(Уйнап карый.)*

**Уллары:**

Бар гаилә бергә җыелдык,
Барыбыз бергә бүген.
Бергә шундый күңелле,
Әллә шулай түгелме?

**Киленнәре:**

Беркем читтә калмасын,
Безнең белән җырласын.
Гаилә белән җыелган көннәр,
Онытырлык булмасын.

*(Җыр башкаралар.)*

**Әби:**

Сөбханалла! Балаларыбыз, оныкларыбыз да үзебез шикелле җыр-моңга гашыйк. Үзебез дә гел сәхнәдә бит! Күп еллар районыбыз Мәдәният йортларын җитәклибез, халкыбызның милли традицияларен түкми-чәчми яшь буынга тапшыру өстендә эшлибез. Татар моңы безнең күңелләрдә!

*(Әби белән бабай җырлыйлар, башкалар кушылалар.)*

Әй, дусларым, сезгә әйтәм,
Гармунчы булсын ярың;
Гармунчының буыннары
Саен мәхәббәт аның.

**Кушымта:**

Суда, суда,
Суда йөзәләсеңме?
Мин сине күрми түзәлмим,
Ә син түзәләсеңме?

**Онык:**

Дәү әниләр, дәү әтиләр,
Әбиләр һәм бабайлар!
Сез булганда тәрбияле
Булып үсәр балалар.

**Уллары:**

Мәңге-мәңге шулай тәрәзләрдә,
Балкып торса иде утыбыз.
Һәрчак безне каршы алса иде,
Әти-әни, туган йортыбыз.

**Бабай:**

Хөрмәт итеп килгән өчен,
Якыннарым олы рәхмәт.
Бөртекләп ашсын тормышка,
Сез теләгән һәрбер теләк.

**Фоторәсемнәр авторларның шәхси архивыннан**

# Бабам портреты

*Наилә Яхина көе һәм сүзләре*




*Хәрби портрет карап тора миңа.*
*Эленгән ул дивар түренә.*
*Пилоткасын йолдыз бизәп тора,*
*Күкрәгендә орден күренә.*

***Кушымта:***
*Бу портретта минем герой бабам!*
*Хәрби кием кигән, ул – горур!*
*Өй түрендә югарыдан карап,*
*Безгә карап һәрчак ул торыр!*

*Бик еш сорыйм, портретына карап,*
*«Булмадымы, – диеп, – куркыныч?»*
*Җавабы бер – карый миңа һаман,*
*Карашлары кыю һәм тыныч.*

***Кушымта.***

*Җиңү көнне, иртә белән торып,*
*Килеп басам портрет каршына.*
*Салют бирәм, кулым сузып аңа,*
*Батыр бабам, Җиңү хакына!*

***Кушымта.***

# Азык, ризык, аш-су төрләре турында мәкальләр

Авыз көнгән ачы катык,
күнмәгән каймактан яхшырак
Аз ашның хәсрәте дә аз.
Азыгы мул хуҗаның кышы кыска булыр.
Алмасаң да – чәй яхшы, ашамасаң да –
май яхшы.
Арык иттән симез котлет пешереп булмый.
Арыш икмәге һәрнәрсәгә баш.
Ачы белән төзәтәләр, тәмле белән бозалар.

## Аш бар өйдә бәрәкәт бар.

Ашсыз өйне эт тә яратмый.
Ашыңа ни салсаң, кашыгыңа шул чыгар.
Бал – ару, җитмеш төрле сырхауга дару.
Бал балчык ашатыр, балан камыр ашатыр.
Бал сөрткәч пычакны да ялыйлар.
Баллы кеше – маллы кеше,
сыерлы кеше – сыйлы кеше.
Бер чынаяк чәйнең кырык ел хәтере бар.
Бер җәем токмач белән туй үтми.
Ботка пешерсәң, маең җитәрлек булсын.
Икмәк югы ямандыр, каты-коты кимертер.
Иписез, тозсыз аш – ярты аш.
Ит ашадың – дәрт алдың,
шулпа ашадың – шифа алдың.
Ит ашасаң, тешкә керә, ашамасаң –
төшкә керә.
Ит сөяксез булмый.
Кеше ашы тәмле була.
Кеше икмәге белән мәңге торып булмый.
Кымыз барда кызык бар.
Көн саен майлы ботка булмый.
Күңел тапмак бер калҗа,
күңел калмак бер калҗа.
Май ботканы бозмас.
Майламый пәрәмәч пешми.



## Кайда коймак, шунда кунак.

Майсыз коймак табага ябыша.
Озак кайнаган аш тәмле була.
Пешкән аш – беткән аш.
Серкә үзен бал санар.
Сөттән ак бул, судан пакъ бул.
Татлы – тешкә дошман,
ачы – ашказанына дус.

## Тату аш, татлы булыр.

Тоз сипкәч, торма да төчерә.
Тәмлене яратсаң, ачысын да ярат.
Үпкәне күпме кайнатсаң да, өресе чыкмас.
Чәе булса, шикәре табылыр.
Чәеңне сал учлап, эчәрсең тынычлап.
Шикәр тәмле булса да,
икмәкне алыштыра алмый.
Язмаган ризык авыздан кире төшәр.
Ярма суда – алтыга, сөттә уникегә ярыла.
Яхшы аш начар кашыкны да алтын итә.

**Рәсем «Татарские пословицы» (Казань: Татар. книж. изд., 1979) китабыннан алынды. Рәссам В. Малякин**



«Татарханә»
проектының «Татар табыны»
рубрикасыннан.
Мастер-классны «Тәмле булсын»
рестораннар челтәре җитәкчесе,
Татар ашлары һәм мәдәнияте
Халыкара ассоциациясе
президенты, Татарстан
Республикасының атказанган
халыкка хезмәт күрсәтү өлкәсе
хезмәткәре, танылган аш-су остасы
**Резидә Кыям кызы**
**ХӨСӘЕНОВА**
алып бара

# Яшел аш

**КИРӘКЛЕ ИНГРЕДИЕНТЛАР:**

*100 грамм яшь кузгалак яфрагы;*
*1 данә суган;*
*70 грамм сөт өсте;*
*25 грамм он;*
*50 грамм үсемлек мае;*
*2 данә йомырка;*
*1,5 литр шулпа;*
*дафнә яфрагы – 1-2 данә;*
*тәменчә тоз, кара борыч.*



1 *Яшел ашны кычыткannan, кузгалактан, чөгендер яфрагыннан, яки шпинаттан пешерергә мөмкин.*



2 *Кайсын булса да, башта яхшылап юабыз, аннан соң пешерергә куябыз, пешкәч, иләккә салып, суын саркытабыз.*



3 *Безнең очракта, пешкән яшь кузгалак яфрагын вак итеп турыйбыз.*



4 *Кайнап торган шулпага 25 грамм он изеп, 50 грамм үсемлек мае, 70 грамм сөт өсте салабыз. Аннары бер баш суган турап, әзерләп куйган кузгалакны өстәп, ашны өлгертәбез. Аш пешеп җитәр алдыннан төрле тәмләткеч үләннәр салабыз.*



5 *Каты итеп йомырка пешереп, ваклыйбыз.*



6 *Тәлинкәләргә бүлгәндә, аш өстенә яшел суган, петрушка сибәбез, вакланган берәр йомырка салабыз. Ашларыгыз тәмле булсын!*

**Фоторәсемнәр Татарстан Республикасының мәдәният өлкәсендә инновацияләр һәм традицияләр саклау ресурс үзәге архивыннан**
**(«Татархана» проектының презентация материаллары җыентыгы ТАТАРХАНӘ / ТАТАРХАНЕ / TATARHANE Казан 2022)**

# *Бергәләп бизибез!*



# Истәлекле даталар
## 2025

## ИЮЛЬ

**1 июль**

Язучы, Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре, Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе, Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Камил Әдһәм улы Кәримовка 75 яшь (1950)

**1 июль**

Композитор, Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе Мәсгудә Ислам кызы Шәмсетдиновага 70 яшь (1955)

**4 июль**

Рәссам, гамәли бизәлеш сәнгате рәссамы, сәнгать фәннәре кандидаты, Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының Б. Урманче исемендәге премия лауреаты Рөстәм Илшат улы Шамсутовка 60 яшь (1965)

**6 июль**

Эстрада артисты, нәфис сүз остасы, Татарстан Республикасының халык артисты Рәшит Хафиз улы Сабировка 70 яшь (1955)

**11 июль**

Композитор һәм дирижёр, ТАССРның һәм РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе, Татарстан Республикасының халык артисты, Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Алмаз Закир улы Монасыйповның тууына 100 ел (1925-2008)

**15 июль**

Актёр, режиссёр, ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе Әхтәм Исмәгъҗан улы Зариповның тууына 90 ел (1935)

**15 июль**

Җырчы, педагог, ТАССРның халык артисты, М. Җәлил исемендәге Республика премиясе лауреаты Римма Мөбарәк кызы Ибраһимовага 75 яшь (1950)

**21 июль**

Баянчы, аккомпаниатор, педагог, Татарстан Республикасының халык артисты, Ф. Туишев исемендәге премия лауреаты Кирам Шәйхиян улы Сатыевка 70 яшь (1955)

**28 июль**

Сәнгать белгече, шагыйрә, тәрҗемәче, Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының Б. Урманче исемендәге, Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Розалина Гомәр кызы Шаһиеваның тууына 80 ел (1945-2024)

## АВГУСТ

**3 август**

Хор дирижёры, ТАССРның һәм РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе, Россия Федерациясенең халык артисты Лима Гали кызы Кустабаевага 80 яшь (1945)

**5 август**

Актриса, Татарстан Республикасының халык артисты Наилә Нургазиз кызы Ибраһимовага 80 яшь (1945)

**19 август**

Пианист, органчы, педагог, музыка-җәмәгать эшлеклесе, Татарстан Республикасының һәм Россия Федерациясенең халык артисты, РФнең атказанган сәнгать эшлеклесе, һәм Россия Федерациясенең Дәүләт премиясе лауреаты Рубин Кәбир улы Абдуллинга 75 яшь (1950)

**24 август**

Композитор, Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе Рөстәм Фәрит улы Зариповка 70 яшь (1955)

**25 август**

Драматург, җәмәгать эшлеклесе, ТАССР, РСФСР, Башкортостан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе, РСФСРның – К.С. Станиславский, Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премияләре лауреаты Туфан Габдулла улы Миңнуллинның тууына 90 ел (1935-2013)

## СЕНТЯБРЬ

**15 сентябрь**

Драматург, ТАССРның һәм РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе Таҗи Кәлимулла улы Гыйззәтнең (Гыйззәтуллин) тууына 130 ел (1895-1955)

**18 сентябрь**

Әдип, дәүләт һәм җәмәгать эшлеклесе, РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе, Татарстан Республикасының халык язучысы, Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе һәм Гаяз Исхакый исемендәге премия лауреаты Гариф (Гарифҗан) Ахунҗан улы Ахуновның тууына 100 ел (1925-2000)

**25 сентябрь**

Композитор, Татарстан Республикасының һәм Россия Федерациясенең атказанган сәнгать эшлеклесе, Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Шамил Харис улы Тимербулатовның тууына 75 ел (1950-2013)

https://kitaphane.tatarstan.ru сайтыннан алынды






**Кадерле укучыларыбыз!**
2025 елның икенче яртыеллыгы өчен «Түгәрәк уен» альманахына республикабызның барлык элемтә бүлекләрендә, яисә «Почта России» сайты аша (https://podpiska.pochta.ru Индекс ПА 183 яисә «Тугарак уен» дип җыярга) онлайн да язылырга мөмкин.

**Индексыбыз – ПА 183**
**Өч айга язылу бәясе – 294 сум 07 тиен**
**Ярты елга язылу бәясе – 588 сум 14 тиен**

БЕРГӘ БУЛЫЙК, ДУСЛАР!